ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ һӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

«Туган (татар) теле» предметы буенча арадаш контроль өчен бәяләү материаллары

ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

«ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛЕ»
ПРЕДМЕТЫ БУЕНЧА АРАДАШ КОНТРОЛЬ ӨЧЕН БӘЯЛӘҮ МАТЕРИАЛЛАРЫ

Казан — 2024

ББК 74.268
Т 23

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2020 елның 25 августында 730 номерлы карары белән расланган
«Татар халкының милли тәңгәллеген саклау»
Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә басыла

Төзүче: Вәһапова Ә.Р., ТРМҮИның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы.

«Туган (татар) теле» предметы буенча арадаш контроль өчен бәяләү материаллары. — Казан: ТР МҮИ, 2024. — 150 с.

Методик ярдәмлек белем бирү оешмаларында эшләүче туган тел (татар теле) һәм әдәбият укытучыларына, мәктәп җитәкчеләренә, милли мәгариф хезмәткәрләренә тәкъдим ителә. Хезмәттә федераль дәүләт белем бирү стандартлары шартларында рус телендә гомуми белем бирү оешмалары (татар телен Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак өйрәнүче) укучыларының татар теленнән белем дәрәҗәсен тикшерү-бәяләүне оештыруның нигезе, тәртибе, куелган таләпләр белән таныштыра, үткәрү өчен биремнәр тәкъдим ителә.

© ТР МҮИ, 2024

КЕРЕШ

Тикшерү-бәяләү эшчәнлеге — укытучының бөтен педагогик хезмәтенең аерылгысыз өлеше һәм укыту сыйфатын яхшыртуның мөһим факторы. Белем бирү программасын, шул исәптән уку предметының аерым өлешен яисә бөтен күләмен, белем бирү программасының аерым модулен үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, өлгерешне контрольдә тоту һәм укучыларны аттестацияләү аша тормышка ашырыла.

Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның белем дәрәҗәсен тикшерү-бәяләү эшчәнлеге түбәндәге норматив документларга нигезләнә:

1. Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы Законы (Федеральный закон «Об образовании в Российской Федерации» от 29.12.2012, № 273-ФЗ);

2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (Закон Республики Татарстан от 22 июля 2013 года № 68-ЗРТ «Об образовании»);

3. Яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартлары (31 май 2021 ел, № 286; 31 май 2021 ел, №286).

Белем бирү программасы нигезендә педагог тарафыннан белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру барышында укучыларның уку казанышларын системалы рәвештә тикшереп тору — укучыларның аерым предметлар буенча өлгерешләре контроле булып тора.

Гомуми белем бирү оешмаларында тикшерү-бәяләү эшчәнлегенең берничә төре бар.

Беренчел тикшерү-белем алу стратегияләрен билгеләргә, укучыларның әзерлек һәм психологик үсеш дәрәҗәләрен исәпкә алып, уку төркемнәрен формалаштырырга мөмкинлек бирә. Бу төр тикшерүнең максаты — предметны үзләштерүнең башлангыч дәрәҗәсен билгеләү, укучыларның индивидуаль-психологик сыйфатларын ачыклау.

Агымдагы тикшерү белем һәм күнекмәләрнең формалашу процессын күзәтергә, дәрестә һәм өйдә уку эшчәнлегенең формаларына һәм ысулларына тиз арада үзгәрешләр кертергә, билгеләрне үз вакытында куярга мөмкинлек бирә.

Арадаш тикшерү аерым теманы, курсның бүлекләрен яки дәресләр блогын үзләштерү нәтиҗәләрен контрольдә тоту максаты белән уздырыла.

Йомгаклау (еллык) тикшерү эшләре — уку елы ахырында үткәрелә һәм укучыларның предмет, курс буенча белем һәм күнекмәләрне үзләштерү дәрәҗәсен ачыкларга ярдәм итә.

Гомуми белем бирү оешмаларында барлык предметлардан, шул исәптән туган (татар) тел һәм әдәбияттан арадаш аттестация эшләрен үткәрү мәҗбүри. Алар һәр чирек материалының үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү өчен дә, яртыеллыкны, еллыкны йомгаклау эше буларак та үткәрелә.

Арадаш аттестация эшенең максатлары:

- укучыларның туган (татар) тел һәм әдәбият предметларыннан теоретик белемнәрен үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү;
- белемнәрне үзләштерү дәрәҗәсен гамәлдәге белем стандартлары таләпләре белән чагыштыру;
- уку-укыту программаларының үтәлешен тикшерү.

Белем бирү оешмаларында арадаш аттестацияне үткәрү ешлыгы

Арадаш аттестация үткәрү уку-укыту процессында белем бирү системасындагы үзгәреш-яңарыш, яңа технологияләрнең үтеп керүе белән тыгыз бәйләнгән. Россия Федерациясенең 2012 нче елның 29 нчы декабрендәге 273-ФЗ номерлы карары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларының 2–8, 10 нчы сыйныф укучылары өчен арадаш аттестация эше уздыру тәртибе расланган. Арадаш аттестация нигезендә укытучы укучыларның укыту материалын ни дәрәҗәдә үзләштерә алуын ачыклый, объектив белемнәрен бәяләп, укучыларның җитешсезлекләрен вакытлы күрә һәм аларны төзәтә ала. Шул исәптән әлеге тикшерү эшчәнлеге укытучыга педагогик процессны оештырудагы кимчелекләрне, үз эшендәге хаталарны да күрергә ярдәм итә. Бу төр тикшерүнең тәрбияви ягы да бар: системалы контроль укучыларны регуляр әзерләнеп йөрергә, дисциплинага өйрәтә. Белемнәрне тикшерү һәм аның сыйфатын бәяләү — укучылар ирешкән белем дәрәҗәсен дәүләт стандарты, минимумы таләп иткән белем һәм күнекмәләргә туры килү-килмәвен чагылдыра.

Бердәм таләпләр нигезендә тикшерү нәтиҗәләре матрицага кертелә, һәр укучы буенча аерым анализ ясала һәм гомумиләштерү ясала, хаталарның тибы билгеләнә, укытучы хаталарның сәбәбен, характерын аңлата. Аннан нәтиҗәләр һәр класс буенча, параллель буенча гомумиләштерелә, динамика ачыклана.

Арадаш аттестацияне уздыру ешлыгы, формалары һәм тәртибе белем бирү оешмасының локаль норматив актында билгеләнә (2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Законның 28 ст. 3 өлеше, 30 ст. 2 өлеше). Димәк, укучыларның өлгерешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру, формаларын, срокларын һәм үткәрү тәртибен билгеләү мәгариф оешмасы компетенциясенә керә.

Арадаш аттестацияне үткәрү ешлыгы белем бирү оешмасының уку планына бәйле, ул укыту предметларын, курсларны, дисциплиналарны (модульләрне), уку эшчәнлегенең башка төрләрен укыту чорлары буенча эзлеклелекне һәм бүленешне билгели. Арадаш аттестацияне үткәрү сроклары укыту-календарь графигында күрсәтелә һәм расписание төзегәндә исәпкә алына. Гадәттә, уку нәтиҗәләрен тикшерүнең түбәндәге төрләре кулланыла:

- кереш тикшерү эше;
- чиреклек тикшерү эшләре;
- агымдагы тикшерү эше;
- еллык (йомгаклау) тикшерү эше.

Һәрбер тикшерү эшчәнлеге үз эченә түбәндәге этапларны ала:

- тикшерүгә әзерлек;
- тикшерүне үткәрү;
- алынган мәгълүматларны анализлау;
- статистиканалитика.

Арадаш аттестацияне үткәрү формалары

Арадаш аттестация формалары белем бирү оешмасының төп белем бирү программасының укыту планында чагылдырыла (бу турыда: 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Законның 2 маддәсенең 9 п.).

Арадаш аттестациянең язма һәм телдән формалары була.

Язма формадагы арадаш аттестация эшләренә түбәндәгеләр керә:

- тестлар;
- комплексы контроль эшләр;
- контроль эшләр;
- диктантлар;
- изложениеләр,
- текст буенча биремнәр;
- иҗади эшләр;
- сочинениеләр;
- эссе;
- рефератлар.

Арадаш аттестациянең телдән формалары түбәндәгеләр:

- докладлар;
- хәбәрләр;
- әңгәмә;
- проектны яклау;
- имтихан.

Шулай ук педагогик күзәтүгә нигезләнгән эксперт бәяләмәсе, агымдагы белем бирү нәтиҗәләрен исәпкә алу кебек формаларны да күрсәтеп китергә мөмкин.

Агымдагы белем бирү нәтиҗәләрен исәпкә алу формасыннан кала арадаш аттестациянең башка формалары контроль-бәяләү процедурасы дигән төшенчәгә берләштереләләр. Контроль-бәяләү процедурасында укучы турыдан-туры яки читтән торып катнаша. Контроль-бәяләү процедурасыннан аермалы буларак, агымдагы белем бирү нәтиҗәләрен исәпкә алу формасында укучының турыдан-туры катнашуы күздә тотылмый, ә бары тик аның агымдагы белем бирү нәтиҗәләре исәпкә алына.

Педагогик күзәтүгә нигезләнгән арадаш аттестация формаларына түбәндәге эш төрләре керә:

- проект бурычларын, ситуацион бурычларны, кейсларны хәл итү буенча төркемнәрдә эшләү;
- төркемле проектны яисә күмәк иҗади эшне башкару;
- программалаштырыла торган дискуссияләр;
- рольле уеннар;
- программалаштырыла торган уку дәресләре.

Эксперт бәяләвенә нигезләнгән арадаш аттестация формаларына түбәндәгеләр керә:

- индивидуаль проектлар;
- иҗади имтиханнар;
- эшләнмәләр, макетлар, рәсем әйберләре, сүз иҗаты продуктлары эшләү.

Педагогик күзәтүгә һәм эксперт бәяләмәсенә нигезләнгән формаларда күзәтү яки эксперт бәяләү шаблоннары кулланыла.

Арадаш аттестация үткәрүне оештыру тәртибе

Арадаш аттестацияне үткәрүне оештыру өчен җаваплы кеше билгеләнә, мәсәлән, укыту-тәрбия (укыту-методика) эше буенча директор урынбасары яисә белем бирү сыйфатын бәяләү буенча директор урынбасары булырга мөмкин. Арадаш аттестация үткәрү турында боерык чыгарып тору мәҗбүри түгел, чөнки ул белем бирү оешмасы приказы белән расланган башлангыч белем бирү төп белем бирү программасының укыту планы һәм календарь уку графигында билгеләнгән. Боерык чыгарылган очракта, мәгариф оешмасы аттестация комиссиясе составын раслау, консультацияләр расписаниесен төзү кебек оештыру моментларын һ.б. чагылдырырга мөмкин. Карарны мәктәп үз мәнфәгатьләреннән һәм оештыру шартларыннан чыгып кабул итә.

Триместр (чиреклек) арадаш аттестациясен оештырганда түбәндәге тикшерү эшләре булырга мөмкин:

- укучыларның агымдагы билгеләре генә исәпкә алына, чирек ахырында контроль эш үткәрелми;
- урта арифметик агымдагы билгеләр һәм чирек ахырында үткәрелгән контроль эш билгеләре исәпләп чыгарыла;
- чирек ахырында үткәрелгән (чиреклек) контроль эш билгесе исәпләнә.

Еллык аттестацияне оештырганда шулай ук төрле вариантлар тәкъдим ителә:

- чирек билгеләре исәпкә алына,
- ел ахырында чиреккә чыгарылган билгеләрнең һәм контроль эш билгеләренең уртача арифметик күрсәткече исәпләп чыгарыла;
- ел ахырында үткәрелгән контроль эш билгесе хәлиткеч роль уйный.

Белем бирү оешмасы башка вариантларны да сайлый ала. Сайланган вариантлар арадаш аттестация турында нигезләмәдә формалар, үткәрү вакыты, агымдагы контроль тәртибе белән беррәттән теркәлә (2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Законның 28 маддәсе).

Әгәр арадаш аттестация контроль-бәяләү процедурасы аркылы уздырылса, аның өчен тиешле вакыт предмет яки курсның эш программасының уку планына чагылыш таба. Бу, мәсәлән, тест, иҗади бирем эшләү, сораштыру уздыру, контроль эш эшләү, реферат яклау, телдән имтихан бирү, әңгәмәләр үткәрү планлаштырганда мөмкин. Арадаш аттестация кысаларында контроль эш эшләтү планлаштырылса, аны үткәрү вакыты төп белем бирү программасының предмет, курс буенча укыту планының гомуми күләменә кертелә. Контроль-бәяләү процедурасын үткәрү датасы һәм вакыты дәрес расписаниесендә теркәлә. Уку көне дәвамында бер контроль эш планлаштырырга, контроль эшләрне икенче-дүртенче дәрестә үткәрергә тәкъдим ителә (мәктәпләрнең СанПин 10.8 п.).

Арадаш аттестация өчен контроль-үлчәү материалларын (КИМ) укытучылар яки директор урынбасарлары әзерләргә мөмкин. Әгәр КИМны укытучы әзерләсә, ул аны директор урынбасары белән килештерә. Педагог үзе әзерләгән КИМ кушымта буларак укытыла торган предмет буенча эш программасына кертелә. КИМ административ хезмәткәр тарафыннан әзерләнсә, килештерү таләп ителми.

Арадаш аттестацияне үткәрү тәртибе

Россия Федерациясенең мәгариф турындагы законы нигезендә укучыларның арадаш аттестация узуга хокукы билгеләнгән. Шуңа күрә укучылар арадаш аттестация узу өчен формаль рәвештә дә, документаль рәвештә дә рөхсәт алырга тиеш түгел. Бу хокук чирек һәм еллык аттестация үтүгә бертигез кагыла.

Агымдагы өлгереш контроленең, шулай ук чиреклек арадаш аттестацияләрнең тискәре нәтиҗәләре укучыны еллык сынау аттестациясенә кертмәүгә сәбәп була алмый. Укучының төп белем бирү программасын үзләштерүгә хокукын үтәүне ассызыклау максатыннан әлеге нигезләмәне белем бирү оешмасының локаль актында теркәп кую зарур.

Әгәр укучы җитди сәбәп белән арадаш аттестациядә катнаша алмаса, аңа контроль эшне башка вакытта язарга яки аны дистанцион рәвештә башкарырга мөмкинлек бирелә. Аттестация датасы күчерелү мәктәп директорының боерыгы белән рәсмиләштерелә. Боерыкта конкрет укучыга датаның күчерелү сәбәбе күрсәтелә.

Укучының арадаш аттестацияне җитди сәбәпсез төшереп калдыру очрагы академик бурыч дип санала (2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Законның 58 маддәсе) һәм академик бурычны укучы бер ел дәвамында, мәктәп урнаштырган срокларда үтәргә тиеш.

Арадаш аттестация нәтиҗәләре укучыларга һәм ата-аналарга (законлы вәкилләргә) мәктәпнең локаль норматив актта билгеләгән срокларында җиткерелә. Укучылар яисә ата-аналар (законлы вәкилләр) аттестация нәтиҗәләре белән килешмәсәләр, белем бирү оешмасының локаль норматив акты белән билгеләнгән тәртиптә дәгъва белдерә алалар. Кагыйдә буларак, укучылар (ата-аналар) һәм педагоглар арасында килеп чыккан ризасызлыклар белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында бәхәсләрне җайга салу комиссиясе тарафыннан тикшерелә.

Укучыга бер ел эчендә белем бирү оешмасы билгеләгән срокларда ике тапкыр академик бурычын ябарга мөмкинлек бирелә (2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Законның 58 маддәсенең 5 өлеше). Елны санаганда авыру чоры төшереп калдырыла.

Арадаш аттестацияне икенче тапкыр үткәрү өчен мәгариф оешмасы комиссия төзи. Аның оешу һәм эшчәнлек тәртибе белем бирү оешмасының локаль норматив актында регламентлана, составы турында директор боерык чыгара.

Дәрестән тыш эшчәнлек курслары буенча арадаш аттестация үткәрелергә тиешме? Арадаш аттестация мәсьәләләрендә РФ-нең 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Законы «уку предметы», «курс», «дисциплина», «модуль» төшенчәләре белән эш итә. Законда курс төшенчәсен дәрестән тыш эшчәнлек курсларына карата кулланып булу турында һәм, димәк, алар буенча арадаш аттестация уздыру турында шәрехләнми. Шулай да дәрестән тыш эшчәнлекнең үзләштерү нәтиҗәләре аттестацияләнергә тиеш булган төп белем бирү программасының аерылгысыз компоненты булуын истән чыгарырга ярамый. Федераль дәүләт стандартларында күрсәтелгәнчә, мәгариф

оешмасының төп белем бирү программасын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләренә ирешүне бәяләү системасы дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлек кысаларында алып барылырга тиеш (18.1.3 ФГОС ООО). Димәк, дәрестән тыш эшчәнлек курслары буенча аерым арадаш аттестация үткәрелмәсә дә, аның нәтиҗәләре барыбер исәпкә алынырга тиеш. Укучыларның дәрестән тыш курсларны үзләштерү нәтиҗәләрен белем алу казанышларын индивидуаль исәпкә алып, портфолио технологиясен кулланып бәяләргә мөмкин.

Нәтиҗәләр:

- Арадаш аттестация нәтиҗәләре укучыларның индивидуаль белем алу казанышлары динамикасын чагылдыра.
- Арадаш аттестация нәтиҗәләрен чиреклек һәм еллык билге буларак теркәп баралар.
- Арадаш аттестация нәтиҗәләре белем бирү оешмасында кабул ителгән бәяләү системасына нигезләнеп билгеләнә. Мәгариф турындагы документларда 5 баллы шкала нигезендә бәяләү кабул ителгән. Мәсәлән, 100 баллы шкала буенча бәяләгәндә, түбәндәге билгеләр системасы тәкъдим ителә:
- «5» — 100–85 балл;
- «4» — 84–65 балл;
- «3» — 64–35 балл;
- «2» — 35 баллдан кимрәк;
- «1» — 15 баллдан кимрәк.

Кагыйдә буларак, 100 баллы шкала 4 сыйныф ахырында комплексны эшләр нәтиҗәләрен бәяләү өчен кулланыла.

Традицион биш баллы шкала — дәүләт аттестациясендә гомуми кабул ителгән бәяләү нигезе. Ул РФ ның бөтен территориясендә белем бирү нәтиҗәләрен теркәүдә бертөрлелекне саклап калырга ярдәм итә.

Традицион биш баллы шкалалардан аерылып торган бәя шкалаларын:

- укучының индивидуаль проект эшләрен;
- дәрестән тыш эшчәнлек программаларын үзләштерү нәтиҗәләрен;
- белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан төзелә торган төп гомуми белем бирү программасының уку планы өлешен үзләштерү нәтиҗәләрен бәяләү өчен кулланырга мөмкин.

Өлгереш журналында чиреклек арадаш аттестация нәтиҗәләре чирек билгесе буларак теркәлә. Еллык арадаш аттестация нәтиҗәләре предмет буенча еллык билге итеп күрсәтелә. Бу билгеләр укучыларның көндәлекләренә һәм өлгереш ведомостьларына кертелә. Бер яисә берничә уку предметы буенча арадаш аттестациянең начар нәтиҗәләре яисә җитди сәбәпсез арадаш аттестациягә килмәү академик бурыч дип таныла.

Башлангыч мәктәптә арадаш аттестация үткәрү үзенчәлекләре

1 нче сыйныфта уку предметлары буенча билгеләр куелмый. Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы уку планы предметларын үзләштерүне контрольдә тотуның түбәндәге формаларын тәкъдим итә:

- педагогик күзәтү;
- шартлы шкалалар;
- «индивидуаль казаныш кәгазьләре»;
- баланың уку казанышлары динамикасын күзәтеп тору графикасы һәм таблицалары.

Укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләрне бәяләү нормалары унберьеллык мәктәпнең башлангыч сыйныфлары өчен төзелгән программаларның таләпләренә нигезләнә һәм укучыларның ана телендә язмача башкарган эшләренә бәя бирү критерийларын үз эченә ала.

1 сыйныфта белем, күнекмәләргә контроль тикшерү ел азагында уздырыла. Контроль эшкә 15 сүздән торган басма шрифтлы текст я күчереп, я диктант итеп язу өчен тәкъдим ителә. Эшне бәяләгәндә, нәтиҗәләрнең программа таләпләренә туры килү-килмәве ачыклана, ишетеп яки күчереп язган текстта хаталар саны 5 тән артмаса, эш канәгатьләнерлек дип санала, нәтиҗәләр телдән аңлатыла.

2–4 сыйныфларда йомгаклау контроль эшләре, гадәттә, грамматик биремле диктант формасында уздырыла. Грамматик бирем сүз һәм җөмләләрне өлешчә яки тулысынча тикшерүдән тора. Диктант һәм грамматик бирем өчен аерым билгеләр куела. Грамматик биремле диктант тексты, өйрәнелгән грамматик материал белән бәйле булырга тиеш, чөнки алар шул материалның үләштерелү дәрәҗәсен һәм укучыларның аны телдән һәм язма сөйләмдә куллана белүен ачыклый.

9 нчы һәм 11 нче сыйныфларда еллык арадаш аттестация үткәрү

9 нчы сыйныфта дәүләт йомгаклау аттестациясе буенча мәҗбүри тапшырылырга тиешле предметтан ахыргы билгене чыгарганда, еллык билгенең уртача күрсәткече исәпкә алына. Укучының имтихан бирмәгән предметларына ахыргы билге предмет буенча укытуның соңгы елында алынган уртача еллык билгегә нигезләнеп куела. Йомгаклау аттестациясенә 9 нчы сыйныфта академик бурычлары булмаган һәм уку-укыту планын яки шәхси уку планын тулысынча үтәгән (барлык уку предметлары буенча 9 нчы сыйныф өчен еллык билге булган) укучылар кертелә.

11 нче сыйныфта предметлар буенча билгеләр чыгарганда, урта гомуми белем бирү программасы буенча белем алучының һәр елда арифметик ярты еллык һәм еллык билгеләренең уртача күләме исәпкә алына.

9 нчы һәм 11 нче сыйныфларда еллык аттестация алдан үткәрелеп, шуның нәтиҗәләре буенча дәүләт йомгаклау аттестациясенә кертелү турында педагогик киңәшмә карары чыгарыла. Укучының дәүләт йомгаклау аттестациясенә кертелүенә нигез булып, инде югарыда күрсәтелгәнчә, академик бурычлар булмау тора. Укучыларны ДЙА-9 һәм ДЙА-11 имтиханнарына кертү турындагы беркетмә датасы беренче имтихан датасыннан иртәрәк булырга тиеш. (Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 14 февралендәге 115 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 5.3 п.).

Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбе рус төркемендә укучыларының татар теленнән белем сыйфатын тикшерү үзенчәлекләре

Рус телендә сөйләшүче укучыларга татар телен укытуның төп максаты — телне аралашу чарасы буларак үзләштерүне тәэмин итү, көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру, укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү, мәдәниара диалогка осталык кебек универсаль күнекмәләр булдыру.

Татар теле дәресләрендә рус телле укучыларга татарча сөйләмне ишетеп аңларга, үз фикерләрен татар теле чаралары ярдәмендә оештырып әйтергә, башкаларның фикерләрен аңлап, телдән һәм язмача күрсәтә белергә өйрәтелә. Бу максатларга ирешүдә коммуникатив технологиягә нигезләнү отышлы.

Татар телендә төрле максатларда һәм ситуацияләрдә аралаша белү осталыгы түбәндәге күнекмәләрнең формалашу белән бергә бара:

- аралашу өчен продуктив лексик минимумны үзләштерү;
- фонетика, лексикология, грамматикага караган материалны төрле аралашу ситуацияләрендә дөрес куллана белү;
- диалогик сөйләм күнекмәләре барлыкка килү;
- аерым темалар буенча монологик сөйләм күнекмәләре формалашу;
- татар телендә текстларны укып аңлау, укыган буенча фикер әйтә белү.

Укучыларның белемен тикшерү-бәяләү эшчәнлеген укыту процессын билгеле бер системага салырлык итеп методик яктан дөрес оештыру зарур. Татар төркемнәрендә татар теленнән белем дәрәҗәләрен диктант, сочинение, инша, тест һ.б. формалар аша тикшерәләр. Ә рус телле укучылар тарафыннан татар теле үзләштерелүенең төп күрсәткече — ул укучыларның өйрәнелгән темалар буенча татарча аралаша белүләре. Шуңа күрә тикшерү-бәяләү эшчәнлегенең төп объекты булып укучыларның татарча сөйләшә белү күнекмәләре тора. Рус төркемнәрендә укучыларның татар теленнән белем һәм күнекмәләрен тикшерүдә язма эшләр һәм телдән сораштыру кулланыла:

- тест биремнәрен башкару;
- текст белән эш;
- диалоглар төзү;

- коммуникатив биремнәр;
- ситуатив биремнәр.

Тест (test) сүзе инглиз теленнән кергән, ул “сынау, тикшерү” дигәнне аңлата. Тест— хәзерге белем бирү системасының иң еш кулланыла торган тикшерү формасы. Тест ярдәмендә укучыларның белемнәрен тикшерү аерым план нигезендә, махсус төзелгән тест биремнәре буенча оештырыла. Укыту тестларының максаты — укучыларның аралашу һәм тел компетенцияләренең дәрәҗәсен билгеләү. Тест сораулары берничә вариантта эшләнә. Алардагы биремнәр логик эзлеклелектә, укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелә. Укучыларга белем бирү, фәнни-тикшеренү эшләрен оештыру, тәрбияләү процессында тестлар куллану мәгълүматны кабул итү, игътибарны көчәйтү, хәтер һәм интеллектны үстерүдә югары күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирә; кешенең ми эшчәнлеген, уйлау сәләтен активлаштыра. Дәрестә даими рәвештә тест уздыру укучыларның активлыгын һәм игътибарын үстерә, биремнәрне үтәгәндә, аларның җаваплылыкларын арттыра.

Тестның башка тикшерү формаларыннан түбәндәге өстенлекле яклары бар:

- белем һәм күнекмәләрне үзләштерү сыйфатын тикшерү тизлеге арта;
- уку материалын тулысынча кабатларга ярдәм итә;
- контроль нәтиҗәләрен математик-статистик эшкәртү мөмкинлеге барлыкка килә һәм, нәтиҗә буларак, педагогик тикшерүнең объективлыгы арта;
- җайлаштырылган тестларны куллану ярдәмендә
- индивидуальләштерү һәм укытуны дифференциацияләү принцибын гамәлгә ашыру мөмкинлеге барлыкка килә.

Тест биремнәренең түбәндәге төрләрен аерып күрсәтәләр:

№	Тест биремнәренең төрләре	Үзенчәлекләре
1.	Тәңгәлләштерү	Уртак темалар яки башка билгеләр буенча бер-ләшкән ике блоктан парлар сайлау.
2.	Альтернатив сайлау	Текстның эчтәлегенә бәйле рәвештә "әйе”/”дөрес”/”туры килә" яки "юк”/”дөрес түгел”/”туры килми" дип җавап бирү.
3.	Дөрес вариант(лар) сайлау	Бирелгән берничә җаваптан бер яисә берничә дөрес вариантны сайлау.
4.	Тәртипкә салу	Аерым репликалардан яки җөмләләрдән текст, диалог төзү.
5	Артык берәмлекне	Бирелгән сүз/ сүзтезмә/ җөмлә төркемендә тема

	билгеләү	яки башка билгеләре буенча туры килмәгәнен билгеләү (алып ташлау, сызу).
6.	Тәмамлау	Мәгънәгә нигезләнеп җөмләне тәмамлау.
7.	Хата төзәтү	Сүз формасында яки җөмләнең структурасында киткән грамматик һәм сөйләм хаталарын төзәтү.
8.	Үзгәртү	Үрнәк нигезендә җөмләне үзгәртү.
9.	Эчтәлекне аңлау һәм тыңлаучыга җиткерү	Текстның эчтәлеген яки мәгънәсен үз сүзләрең белән тапшыру.
10.	Тәрҗемә итү	Тәрҗемә итү.
10.	клоуз-тестлар	Укучы бирелгән текстта төшеп калган элементлар-ны торгызырга тиеш.

Тест төрләренә мисаллар.

1. Хәрефләр белән цифрларны тоташтырып, мәкальләрне җыегыз.

1) Олыласаң олыны а) кеше сине мактасын

2) Үзеңне үзең мактама, б) кешедән сора.

3) Үзең белмәсәң,в) ташка кадак кагар.

4) Җиде кат үлчә,г) тәмләп ашарсың.

5) Тырышып эшләсәң, д) бер кат кис.

5) Тырышкан табар,е) олыларлар үзеңне

Ачкыч: 1 е, 2 а, 3 б, 4 д, 5 г, 6 в.

2.

а) Текстны укыгыз. Текстның эчтәлегеннән чыгып, “текстка туры килә” яки “текстка туры килми” дигән җавапларның дөрес вариантын сайлагыз.

Урманда аю баласы яши. Аның исеме Әппәс. Әппәс бик эшчән була. Ул яз көне яшелчәләр утырта. Ул кишерне чишмәдә юа һәм ашый башлый. Әппәс янына Куян килә. Ул Куянны сыйлый.

1) Болында аю баласы яши.

а) текстка туры килә б) текстка туры килми

2) Әппәс — ялкау аю.

а) текстка туры килә б)текстка туры килми

3) Әппәс яз көне агачлар утырта.

а) текстка туры килә б)текстка туры килми

4) Аю баласы Куянны кишер белән сыйлый.

ә). Текстны укыгыз. Әгәр сез әлеге фикер белән килешәсез икән, “+” куегыз, килешмәсәгез, “ — “ куегыз.

Мин бүген иртә тормадым. Мәктәпкә барырга, дәрес әзерләргә кирәкми. Ринат күптән урамда йөри икән. Ринат миңа:”Көрәк алып чык әле!”—дип кычкырды. Мин көрәк алып чыкмадым. Ринат миңа:”Өйгә кереп кит”,—диде.

1) Бүген иртә тордым.

2)Мәктәпкә барырга кирәк.

3) Ринат урамда йөри.

4) Ринат миңа чана алып чыгарга кушты.

5) Мин көрәк алып чыктым.

6) Ринат мине чана шуарга чакырды.

3.

а) *куян йөрәкле* фразеолгизмын кайсы сүз белән алмаштырып була?

1) тыйнак

2) усал

3) акыллы

4) куркак

ә) Антоним сүзләр рәтен күрсәтегез.

1) бара, ала

2) көлә, елмая

3) каршылый, озата

4) саргая, кызара

4.

а) Җөмлә килеп чыксын өчен, җәмлә өлешләрен нинди эзлеклелектә куярга кирәк?

А) кечкенә инешләр дә

Ә) безнең республикабызны

Б) зур елгалар да

В) бик ямьләндерә

Ачкыч: Ә, А, Б, В

ә) Текст килеп чыксын өчен, җәмлә өлешләрен нинди эзлеклелектә куярга кирәк?

А) Ашый торган ризыкта витаминнар булуы бик мөһим.

Ә) Һәркем сәламәт булу өчен тырышырга тиеш.

Б) Шуңа күрә кешеләр ит тә, сөт ашамлыклары да, яшелчәләр дә, җиләк-җимеш тә ашарга тиеш.

В) Сәламәт булырга теләсәң, иң беренче чиратта яхшы тукланырга кирәк.

1) Ә, В, Б, А

2) В, Ә, Б, А

3) Ә, В, А, Б

4) В, Ә, А, Б

Ачкыч: Ә, В, Б, А

б) Диалог килеп чыксын өчен, репликаларны кирәкле тәртиптә куегыз (цифрлар эзлеклелеген күрсәтегез).

А) Әйе, ул вакытта урында булам. Сәгать бердә киңәшмәгә китәм.

Ә) Анда түгәрәк печать юк. Шуңа күрә яңа справка алып килергә кирәк.

Б) Иртәгә врачка барырга һәм справка алып килергә кирәк.

В) Соңга калмагыз, зинһар өчен.

Г) Мин кичә справканы алып килдем бит.

Д) Ярый, мин җитешергә тырышам.

Е) Яхшы, мин иртәгә анда барам һәм сезгә справканы кертермен. Сәгать уникедә сез эш урынында буласызмы?

Җавап:_____

Ачкыч: Б, Г, Ә, Е, А, Д, В.

5. Һәр юлда артык сүзне сызыгыз.

1) ярдәм, ышанычлы, кешелекле

2) авылдаш, әңгәмәдәш, ватандаш

3) әдәпле, уңган, тупас

4) сәламләү, тәмамлау, исәнләшү.

Ачкыч: 1) ярдәм, 2) әңгәмәдәш, 3) тупас 4), тәмамлау

6. Һәр юлда мәгънәләре буенча туры килә торган фигыльләрне яз.

1) Муса Җәлил биш елга якын Казанда _____.

2) Татарстанның бай тарихы музейларда _____.

3) Музей залларында меңләгән экспонат _____.

4) Антарктидадагы иң биек тауларның берсе Муса Җәлил исемен _____.

5) Җәлилне “татар Фучигы” дип _____.

Ачкыч: 1) яшәгән; 2) чагыла (саклана); 3) саклана; 4) йөртә; 5) атыйлар.

ә) Җөмләнең дәвам итеп бетер.

1) Кояш чыга һәм ... _____.

2) Дәрес башланды, ләкин ... _____.

3) Диңгезгә карыйм да ... _____.

4) Кемдер шалтыраткан, әмма ... _____.

7.

а) Җөмләләрне укыгыз, грамматик һәм сөйләм хаталарын төзәтегез. Дөрес вариантны языгыз.

1). Урман — кешенең якын дус. — _____.

2). Ул үзенең матуры, гүзәллеге белән табигатькә ямь бирә. — _____.

3). Әйе, урман матурда, файдалы да. — _____.

4). Ләкин урманга булыша, сакларга кирәк! — _____.

8. Бирелгән җөмләләрдән сорау һәм инкарь җөмләләр төзегез.

Үрнәк: Яз килә. — Яз киләме? Яз килми.

1) Агачлар яшел яфрак яра. — _____.

2) Урманда умырзаялар күренде. — _____.

3) Шомырт ап-ак чәчәк аткан. —_____.

4) Аланда аллы-гөлле чәчәкләр үсәчәк. — _____.

9. Эчтәлекне аңлау һәм тыңлаучыга җиткерү характерындагы тестларны укытуның өлкән баскычында куллану отышлы. Башлангыч һәм урта баскыч сыйныфларында мәкальләр, әйтемнәр һәм зур булмаган текстлар кулланыла. Мәкальләрне укыгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз.

1) Телләр белгән — илләр гизгән . — _____.

2) Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын. — _____.

3) Яхшы сүз җанга рәхәт. — _____.

4) Җиде кат үлчә, бер кат кис. — _____.

10.

а). Җөмләләрне тәрҗемә итегез.

Мою подругу зовут Алсу. — _____.

Ей 17 лет. — _____.

Она студентка. — _____.

Она учится в колледже. — _____.

Она хочет стать дизайнером. — _____.

Она очень талантливая и трудолюбивая. — _____.

Она хороший друг. — _____.

Ей нравится готовить национальные блюда. — _____.

ә). Диалогны тәрҗемә итегез.

— Илдар, сиңа ничә яшь?

— Биш.

— Ә үзең минем зонтиктан да тәбәнәгрәк.

— Ә сезнең зонтикка ничә яшь соң?

_____.

_____?

_____.

_____.

_____?

11. Клоуз-тест текстны укып аңлау, төшереп калдырылган берәмлекләрне торгызуны күздә тота. Мондый биремне уңышлы башкару укучының текстны никадәр тиз аңлый алуына һәм анда тасвирланган вакыйгалар яки фактлар

арасындагы бәйләнешне билгели алуына турыдан-туры бәйле. Мондый тест өйрәнелә торган телнең лексикасын белү дәрәҗәсен билгели.

Клоуз-тестка матур әдәбият әсәрләреннән өзекләр сайлана, анда билгеле бер ешлыкта (мәсәлән, 5 нче, 7 нче һ. б.) сүз төшереп калдырыла. Төшереп калдырылган сүз я мөстәкыйль, я ярдәмче сүз төркеменә карарга мөмкин. Тест өчен сайланган текст төзелеше буенча бөтен, мәгънәсе буенча тәмамланган фактларны яки вакыйгаларны бәян итәргә, ә төшеп калдырылган сүзләр контекст хисабына шактый җиңел торгызылырлык булырга тиеш.

Текст укучылар санына туры китереп әзерләнә һәм таратыла. Укучылар үзлектән текстны ике тапкыр укыйлар. Беренче укыганда алар аның гомуми эчтәлеге белән танышалар, икенче укыганда — текстның эчтәлеген торгызу өчен кирәкле сүзләр белән буш урыннарны тутыралар.

Укучылар төшеп калган сүзләрне клоуз-тестка яки махсус сораштыру кәгазьләренә язалар. Укучының биремне дөрес башкаруы текст эчтәлегендәге лингвистик һәм экстралингвистик факторларның үзара бәйләнешен аңлап эш итүе, лексик материалны үзләштерүе турында дәлил булып тора. Шулай итеп, клоуз-тест ярдәмендә уку күнекмәләренең формалашуы һәм лексиканы үзләштерү дәрәҗәсе шактый төгәл һәм объектив билгеләнә.

Клоуз-тест шулай ук чит телле сөйләмне ишетеп аңлауны тикшерү чарасы да булырга мөмкин. Аудированиене өчен клоуз-тест әзерләгәндә, укучыларга таныш лексик материал һәм гади синтаксик структуралар булган текстны сайлап алырга кирәк. Мәсәлән:

Бүген безгә кунак апа ... . Ул миңа матур курчак ... . Курчакның күзләре зәп-зәңгәр, чәчләре ... һәм сап-сары. Күлмәге дә ... матур. Мин кунак апага ... әйттем. Миңа бүләк бик ... .

Безгә дус кызым Оля ... . Оляга да курчак ошады. ... курчакка Алсу исеме бирдек. ... икәү бергә уйнадык. Безгә ... күңелле булды. Иртәгә Оляга ... кунакка керәм. (55 сүз).

Ачкыч: 1— килде, 2 — бүләк итте, 3 — озын, 4 — бик, 5 — рәхмәт, 6 — ошады, 7 — керде, 8 — без, 9 — без, 10 — бик, 11 — мин.

Клоуз-тестларның сыйфатын бәяләү түбәндәгечә башкарыла. Һәр дөрес җавап өчен укучы 1 балл ала, дөрес булмаган җавап яки җавап булмаган очракта 0 балл куела. Әгәр укучы җавабында таләп ителгән сүзне түгел, ә аңа якын мәгънәле сүзне сайласа, уку яки аудирование күнекмәләрен контрольдә тотканда, ул 1 балл, ә агымдагы контроль эш уздырганда — 0,5 балл ала.

Текст буенча эш төрләре

Әлеге эшчәнлек текстны уку, текст буенча эшләү күнегүләрен үз эченә ала:

- текстны уку (чиратлап, рольләргә бүлешеп һ.б.);

- текст буенча сорауларга җавап бирү;
- эчтәлеген сөйләү (язу);
- ахырын (башын, уртасын) уйлап язу;
- темасын, микротемаларын билгеләү, планын төзү;
- конспектлау;
- аннотация язу;
- анализлау;
- диалогик, монологик сөйләм оештыру.

Сөйләм дәрәҗәсен контрольгә алуда диалог, монолог төзү формасындагы эш төрләре бик отышлы. Мәсәлән:

1. Диалогның башын уйлап языгыз.

— ...
— ...
— ...
— Миңа дәфтәр кирәк иде.

2. Диалогны тулыландырыгыз.

— Сәлам, Айнур!
— ...
— Кая барасың?
— ...
— Нәрсә аласың?

3. Диалогны дәвам итегез.

— Исәнмесез, Алсу апа!
— Исәнме, Марат!
— Алсу апа, мина дәреслекләр кирәк.
— ...?
— ...

4. Диалогны тәмамлагыз.

— Син әниеңә булышасыңмы?
— Әйе, булышам.
— Ничек булышасың?
— ... .

5. Монологны диалогка үзгәртегез.

Минем этем бар. Аның кушаматы — Актүш. Актүш өйдә яши. Ул бик матур, акыллы. Ул безнең белән уйный.

— Синең этең бармы?
— Әйе, минем этем бар.
— Аның кушаматы нинди?

— Аның кушаматы — Актүш.

— Ул урамда яшиме?

— Юк, ул өйдә яши.

— Актүш нинди?

— Ул матур һәм акыллы эт.

— Актүш уйнарга яратамы?

— Әйе, Актүш безнең белән уйный.

6. Диалогтан монолог төзегез.

— Син каникулда кая барасың?

— Мин Казанга барам.

— Казан матур шәһәрме?

— Әйе, бик матур!

— Анда нәрсәләр бар?

— Казанда театрлар, парклар, урамнар, мәктәпләр бар.

— Ә син кайсы җиргә барасың?

— Мин циркка барам.

Мин каникулда Казанга барам. Казан — матур шәһәр. Анда театрлар, парклар, урамнар, мәктәпләр бар. Казанда мин цирка барам.

7. Билгеле бер темага караган диалоглар төзү.Мәсәлән, ял көнен үткәрү турында иптәшегез белән әңгәмә корыгыз.

— Сәлам, Ирина!

— Сәлам, Гүзәл! Ял көнен ничек үткәрдең?

— Мин ял көнен бик яхшы үткәрдем. Әнием белән циркка бардык. Мина бик ошады. Ә син?

— Мин дусларым белән кинога бардым.

8. Раслау (инкарь итү/сорау/ каршы килү/ киңәш бирү/үтенү һ.б.) репликасы булган диалог төзегез.

— Алсу, син өйдәме?

— Әйе, мин өйдә.

— Нишлисең?

— Китап укыйм.

— Нинди китап?

— Бик кызыклы китап. Файдалы киңәшләр язылган. Син дә бу китапны укып чык! Мин сиңа бирермен.

9. Бирелгән схема буенча диалог төзегез. Мәсәлән:

— *сорау — каршы сорау — җавап:*

— Син музейга барасыңмы?

— Нинди музейга?

— Тукай музеена.

– *чакыру — риза булмау:*

— Әйдә, Алсу, музейга барыйк!

— Юк, бара алмыйм. Дәресләрем күп.

— *хәбәр итү — раслау:*

— Айрат, бүген дәрестән соң музейга барабыз!

— Әйе, дустым, беләм, белдерүне укыдым.

10. Рәсем, картина буенча диалог төзү.

Укучыларның диалогик сөйләме түбәндәге критерийлардан чыгып бәяләнә:

— диалогик сөйләмнең структур яктан оешкан булуы;

— аралашу максатына ирешү, теманың ачылуы;

— репликаларның лексик-грамматик яктан дөрес булуы;

— этикет үрнәкләрен урынлы кулланулы;

— актив һәм итагатьле әңгәмәдәш булу.

Коммуникатив биремнәраркылы аерым лексик һәм грамматик формаларны үзләштерүне тикшерү тормышка ашырыла. Мондый тип күнегүләрнең әһәмияте шунда: укучы фикерен җиткерү өчен өйрәнелә торган тел чараларын үзе җыя һәм укучыда эчке сөйләм эшчәнлеге башлана. Ә бу аралашу процессына өйрәтүдә бик мөһим чара. Мәсәлән:

К тебе пришел твой друг. Как ты представишь его своим родителям? — *Әти, әни! Бу минем иң якын дустым Артур!*

Ты уезжаешь к своим друзьям в деревню, как ты об этом сообщишь бабушке? — *Әбием, мин авылга үземнең дусларым янына китәм.*

Сегодня в школе состоится концерт. Уточни у Саши, будет ли он участвовать. — *Саша, син бүген мәктәптә буласы концертта катнашасыңмы?*

Спроси у друга о том:

– пойдет ли он сегодня в городскую библиотеку;

– какую книгу он читал на каникулах;

– пригласит ли он друзей на день рождения;

– как он собирается провести выходные.

Поинтересуйся у друга:

– как у него дела;

– будет ли он участвовать в соревнованиях;

– интересна ли эта книга.

Сообщи о том:

– что завтра будет родительское собрание;

– что вы вчера ходили в кино;

– что они были в гостях;

– что завтра в городе будет кросс.

Посоветуй подруге:

– чтобы она не опаздывала на урок;

– чтобы она прочитала книги татарских писателей;

– чтобы она сходила в музей;

– чтобы она каждый день готовилась к урокам.

Предложи подруге:

– бегать по утрам;

– пойти в лес;

– поиграть в лото;

– сходить в кукольный театр.

РУС ТЕЛЕНДӘ БАШЛАНГЫЧ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ (ТАТАР ТЕЛЕН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ БУЛАРАК ӨЙРӘНҮЧЕ) УКУЧЫЛАРНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕННӘН БЕЛЕМ СЫЙФАТЫН ТИКШЕРҮ КОНТРОЛЬ ЭШ ҺӘМ АЛАРНЫ БӘЯЛӘҮ ҮРНӘКЛӘРЕ

3 нче сыйныф

Кереш контроль эш

1 нче вариант	2 нче вариант
1. Напиши по образцу: *Укучы — укучылар* Мәктәп — Бала — Көн — Урам —	**1. Напиши по образцу:** *Укучы — укучылар* Дәфтәр — Китап— Төн — Урман —
2. Найди лишнее слово 1) укытучы 2) укучы 3) дәрес 4) керпе 5) дәфтәр	**2. Найди лишнее слово** 1) әти 2) әни 3) әтәч 4) бабай 5) әби
3. Найди слово, отвечающее на вопрос *нинди?* 1) сәгать 2) тәмле 3) такта 4) йорт 5) тарак	**3. Найди слово, отвечающее на вопрос *нинди?*** 1) сарык 2) акбур 3) тел 4) яши 5) ак
4. Поставь в конце каждого предложения нужный знак 1) Син укучымы 2) Марат мәктәптә укый	**4. Поставь в конце каждого предложения нужный знак** 1) Сыйныфта ничә укучы 2) Бабай радио тыңлый
5. Напиши, кто выполняет эти действия ... яшибез ... кайтам ... йөри	**5. Напиши, кто выполняет эти действия** ... яраталар ... барасың ... укый
6. Переведи рассказ Летом я купаюсь в реке, загораю на	**6. Переведи рассказ** Летом я купаюсь в реке, загораю на

солнце. С папой ловим рыбу. Летом хорошо. Я люблю лето.	солнце. С папой ловим рыбу. Летом хорошо. Я люблю лето.
Контроль язма эшне бәяләү критерийлары: Гомуми балл —14 7 баллдан азрак — “2” 14–13 балл — “5” 12–11 балл —“4” 10–8 балл — “3”	

Агымдагы контроль эшләр

1 нче контроль эш

1 вариант	2 вариант
1. Найди лишнее слово Өй, өч, бүлмә, тәрәзә. **2. Ответь на вопросы** Кая? Кайдан? Кайда? Мәктәп... Мәктәп... Мәктәп... **3. Допиши предложения** Мин мәктәптә ... . Ул урамга ... . Без стадионда ... . Сез цирктан ... . **4. Составляем предложения** Айратның китабы ... . Ләйсәннең өстәле ... . Ленаның бүлмәсе ... **5. Напиши по-татарски** Наша школа, мои книги, твой стул, ее комната ***Ответь на вопросы** Сез ничәнче сыйныфта укыйсыз? Дәресләр сәгать ничәдә башлана? Бүген ничә дәрес була? Дәрестә сез нишлисез? Тәнәфестә сез ничек ял итәсез?	**1. Найди лишнее слово** Егерменче, бишенче, уналтынчы, укучы. **2.Ответь на вопросы** Кая? Кайдан? Кайда? Бүлмә... Бүлмә... Бүлмә... **3. Допиши предложения** Мин татарча ... . Дәрестә без ... . Без мәктәпне ... Алар өйгә ... . **4. Составляем предложения** Максимның урындыгы ... .Сашаның дәфтәре ... . Азатның мәктәбе ... . **5. Напиши по-татарски** Ваша квартира, его дом, наш город, твоя деревня ***Ответь на вопросы** Сез ничәнче сыйныфта укыйсыз? Дәресләр сәгать ничәдә башлана? Бүген ничә дәрес була? Дәрестә сез нишлисез? Тәнәфестә сез ничек ял итәсез?
Контроль язма эшне бәяләү критерийлары: Гомуми балл — 14 7 баллдан азрак — “2” 14–13 балл — “5” 12–11 балл — “4” 10–8 балл — “3”	

2 нче контроль эш

1 вариант	2 вариант
1. Найди лишнее слово Барды, белә, кайтты, котлады **2. Составь предложения** Үрнәк. Әни ботка пешерде. Ул салат яса... . Син чәй эч... Әни өчпочмак пешер... . Без өйгә кайт... **3. Составь предложения** Үрнәк. Кар яуды. — Кар яумады. Кыш җитте. Боз каплады. Җил исте. **4. Допиши предложения** Кичә мин мәктәпкә ... . Дәресләр сәгать сигездә ... . Без чәй ... , торт ... . **5. Ответь на вопросы** Сәгать ничәгә кадәр укыйсыз? Җәйгә кадәр ничә ай бар? *** Напиши об одном времени года**	**1. Найди лишнее слово** Бетә, булды, карады, килде. **2. Составь предложения** Үрнәк. Әни ботка пешерде. Без токмач аша... . Алсу тиз үс... . Ул өй эше әзерлә... . Мин сине ярат... **3. Составь предложения** Үрнәк. Кар яуды.. — Кар яумады. Кар эреде. Тамчы тамды. Кояш чыкты. **4. Допиши предложения** Кичә без әбигә кунакка ... . Әби ... Мин китап ... , телевизор ... . **5. Ответь на вопросы** Сәгать ничәгә кадәр уйныйсыз? Дәрескә кадәр ничә минут бар? *** Напиши об одном времени года**
Контроль язма эшне бәяләү критерийлары: Гомуми балл — 14 7 баллдан азрак — “2” 14–13 балл — “5” 12–11 балл — “4” 10–8 балл — “3”	

3 нче контроль эш

1 вариант	2 вариант
1. Напиши по образцу: *Урам — урамнар.* Урын, бина, һәйкәл, манара. **2. Найди противоположное по смыслу слово** Кичә — Ерак — **3. Ответь на вопросы** Ул кем? Син аны яратасыңмы? Аның исеме ничек? Аннан кем китап алды? Аңа ничә яшь? Аңарда нинди сүзлек бар?	**1. Напиши по образцу:** *Урам — урамнар.* Сарай, театр, кунакханә, мәйдан. **2. Найди противоположное по смыслу слово** Иртәгә — Монда — **3. Ответь на вопросы** Син укучымы? Синең китабың матурмы? Сиңа ничә яшь? Әниең сине яратамы? Синнән кем китап алды? Синдә телефон бармы?

4. Допиши предложения Өйдә мин идәнне үзем ... . Син тактаны үзең .. . Без сыйныфны үзебез ... . **5. Ответь на вопросы** 1) — Иртәгә сиңа кая барырга кирәк? — .. . . 2) — Керергә ярыймы? — ... . **6. Составь вопросы** — ...? — Без —укучылар. — ...? — Безнең бакчабыз зур һәм матур. —...? — Кичә безгә кунаклар килде. *** Переведи** Мин — укучы. Минем тубым бар. Миңа 8 яшь. Әбием мине ярата. Дустым миннән китап алды. Миндә татарча-русча сүзлек бар.	**4. Допиши предложения** Ул гөлләргә үзе ... . Сез тортны үзегез ... . Алар савыт-сабаны үзләре ... . **5. Ответь на вопросы** 1) — Дәрестә кемне тыңларга кирәк? — ... . 2) — Чыгарга мөмкинме? — ... . **6. Составь вопросы** — ...? — Әби безне ярата. — ...? — Кунаклар бездән сәгать алтыда киттеләр. — ... ? — Бездә кечкенә эт бар. *** Переведи** Мин — укучы. Минем тубым бар. Миңа 8 яшь. Әбием мине ярата. Дустым миннән китап алды. Миндә татарча-русча сүзлек бар.
Контроль язма эшне бәяләү критерийлары: Гомуми — 20 балл 20–18 балл — “5” 17–15 балл —“4” 11–14 балл — “3” 10 баллдан азрак — “2”	

4 нче контроль эш

1 вариант	2 вариант
1. Составь предложения **Үрнәк. Алар җидәү.** Без дүрт.. . Малайлар ун.. . **2. Напиши по-татарски** Для кого? Для мальчиков, для друзей, для детей, для учеников. **3. Допиши нужные окончания** Нәрсә? Мәктәп. Нәрсәнең? Мәктәп... .	**1. Составь предложения** **Үрнәк. Алар җидәү.** Сез өч.. . Кызлар биш. .. . **2. Напиши по-татарски** Для чего? Для садов, для городов, для деревень, для школ. **3. Допиши нужные окончания** Кем? Укучы. Кемнең? Укучы.. .

Кая? Мәктәп.. . Нәрсәне? Мәктәп.. . Кайдан? Мәктәп... . Кайда? Мәктәп.. . **4. Допиши нужные окончания** Сабантуй.. ярышлар була. Без Сабантуй.. барабыз. Балалар Сабантуй.. яраталар. Без Сабантуй .. машина белән кайтабыз. **5. Напиши по образцу:** *Без бармадык. Без бардык.* Сез килмәдегез. Алар уйнамадылар. Син йөзмәдең. **6. Переведи** Йөзәләр — Уйныйлар — Җыялар — Каршылыйлар —	Кемгә? Укучы.. . Кемне? Укучы.. . Кемнән? Укучы.. . Кемдә? Укучы.. . **4. Допиши нужные окончания** Сабантуй.. ярышлар була. Без Сабантуй.. барабыз. Балалар Сабантуй.. яраталар. Без Сабантуй .. машина белән кайтабыз. **5. Напиши по образцу:** *Без бармадык. Без бардык.* Ул эшләмәде. Без кызынмадык. Мин йөгермәдем. **6. Переведи** Кызыналар — Озаталар — Ял итәләр — Көтәләр —
Контроль язма эшне бәяләү критерийлары: Гомуми — 20 балл 20–18 балл — “5” 17–15 балл —“4” 11–14 балл — “3” 10 баллдан азрак — “2”	

5 нче сыйныф

Кереш контроль эш

1 вариант	2 вариант
1. Найди антонимы Көн — Матур — Кечкенә — **2. Переведи вопросы, напиши 2 предложения** Кто? Какой? Куда? **3. Скажи о том,**	**1. Найди антонимы** Ак — Җәй — Җылы — **2. Переведите вопросы, напиши 2 предложения** Что? Что делает? Где? **3. Скажи о том,**

— сколько тебе лет; —в каком классе ты учишься. **4. Допиши нужные слова** Беренче сентябрь … бәйрәме. Мәктәптә күңелле ... уйный. **5. Допиши окончания** Укучылар мәктәп... баралар. Бүген мәктәп... зур бәйрәм. Мин мәктәп... кайтам.	— что ты учишься в школе; — сколько мальчиков и девочек в классе. **4. Допиши нужные слова** Мин укытучыга ... бирәм. Бүген укучылар ... киенгәннәр. **5. Допиши окончания** Укучылар сыйныф... керәләр. Мәктәп... күңелле музыка уйный. Мин китапханә... китаплар алам.
Контроль язма эшне бәяләү критерийлары: Барлыгы: 13 балл. 5 баллдан түбән — «2»ле куела. 13–12 балл — «5»ле, 11–9 балл — «4»ле, 8–5 балл — «3»ле.	

Агымдагы контроль эшләр

“Без мәктәптә” темасына контроль эш

1 вариант	**2 вариант**
1. Допиши предложения 1. Каләм белән..... . 2. Чүпрәк белән.... . 3. Линейка белән... . **2. Найди антонимы слов** әдәпле — начар — тырыш — . **3. Определи все аффиксы в словах** Күзләремне, открыткагыз. **4. Узнай у друга,** — какие отметки сегодня он получил; — сколько уроков было; — какой был первый урок. **5. Попроси у друга:** — тетрадь в линейку; — новую тетрадь.	**1. Допиши предложения** 1. Бетергеч белән..... . 2. Дәреслек белән.... . 3. Карандаш белән... . **2. Найди антонимы слов** тәрбияле — акыллы — ялкау — . **3. Определивсе аффиксы в словах** Дәфтәремне, китаплары. **4. Узнай у друга,** — сделал ли он домашнее задание; — надо ли ему тетрадь в клетку; — какую оценку он получил. **5. Попроси у друга:** — красный карандаш; — ластик.

Контроль язма эшне бәяләү критерийлары: Барлыгы: 13 балл. 5 баллдан түбән — «2»ле куела. 13–12 балл — «5»ле, 11–9 балл — «4»ле, 8–5 балл — «3»ле.

“Без өйдә булышчы” темасына контроль эш

1 вариант	2 вариант
1. Поставь вопросы к выделенным словам. 1. Гүзәл әнисенә булышмады. 2. Марат әтисен ярата. **2. Вместо многоточий вставь нужные окончания.** 1. Әни, урамга чы(к)... мөмкинме? 2. Әни, уйна... ярыймы? **3. Скажи о том , что** — надо сходить в магазин; — дома нельзя прыгать. **4. Как ты спросишь у друга,** — убирает ли он постель; — идет ли он в школу; — идет ли он в бассейн. **5. Переведи** 1. Айрат старше меня на год. 2. Сарафан удобнее юбки. 3. Айдар — воспитанный мальчик. 4. Наше село большое, красивое.	**1. Поставь вопросы к выделенным словам.** 1. Әнисе балаларны мактады. 2. Наил белән Галия кибеткә бармадылар. **2. Вместо многоточий вставь нужные окончания.** 1. Гөлләргә еш су си(п).... ярамый. 2. Өйдә әнигә булыш.... кирәк. **3. Скажи о том , что** — надо помочь маме; — надо помыть посуду. **4. Как ты спросишь у друга,** — убирает ли он постель; — идет ли он в школу; — идет ли он в бассейн. **5. Переведи** 1. Айрат младше меня на год 2. Сарафан красивее юбки. 3. Айдар — вежливый мальчик. 4. Наш город красивый, чистый.
Контроль язма эшне бәяләү критерийлары: Барлыгы: 13 балл. 5 баллдан түбән — «2»ле куела. 13–12 балл — «5»ле, 11–9 балл — «4»ле, 8–5 балл — «3»ле.	

“Дуслар белән күңелле” темасына контроль эш

1 вариант	2 вариант
1. Переведи слова Дус, дуслык, бергә, әдәпле, алып бара, алып керә, үпкәләде, күңелсез.	**1. Переведи слова** Ярдәмчел, күңелле, күршеләр, игътибарлы, алып чыга, алып кайта, гадел, шаян.

2. Предложи другу: — вместе поиграть; — вместе пойти в школу. **3. Спросите у друга,** — готовил ли он сегодня домашнее задание; — нравится ли ему спорт; — любит ли он каши; — любит ли он мороженое. **4. Дополни диалог** — ...? — Әйе, минем песием бар. — ... ? — Аңа бер яшь. — ... ? — Ул бик акыллы һәм шаян. **5. Подчеркни слова, отвечающие на вопрос *нинди?*** Минем дустым бар, аның исеме — Азат. Ул яхшы дус, ярдәмчел иптәш. Без зур, яңа мәктәптә укыйбыз. Бергә түгәрәккә йөрибез, урамда футбол уйныйбыз, кызыклы кинолар карыйбыз.	**2. Предложи другу:** — вместе сделать домашнее задание; — вместе пойти в кино. **3. Спросите у друга,** — на какой кружок он ходит; — выйдет ли он вечером на улицу. — когда у него день рождения; — любит ли он читать книги. **4. Дополни диалог** — ...? — Әйе, минем дустым бар. — ... ? — Ул бишенче сыйныфта укый. — ... ? — Ул бик яхшы дус. **5. Подчеркни слова, отвечающие на вопрос *нинди?*** Минем дустым бар, аның исеме — Алсу. Ул бик акыллы, ярдәмчел, яхшы кыз. Без бик матур һәм зур йортта яшибез. Бергә уйныйбыз, дәрес әзерлибез, мәктәпкә йөрибез.
Дәресләр тәмамлануын белдереп, кыңгырау шалтырады. Рәсим ашыкмый-кабаланмый урыныннан торда. Сумкаларына дәфтәр, китапларын тутыру белән мәшгуль булган Илһам ручкасының юкка чыкканын сизми дә калды. Рәт арасыннан узганда, Рәсим ручканы эләктергән иде инде. Ничек шулай оста, тиз эләктергәндер, соңыннан үзе дә гажәпләнде ул моңа. Илһам, берни сизмичә, сумкасын күтәреп, сыйныф бүлмәсеннән чыгып китте.

Рәсимнән дә бәхетле малай юк иде бу минутларда. Бизәкле ручка аның кесәсендә иде.

Өйләренә дә алтын кош тоткандай очынып кайтып керде. Кесәсеннән ручканы алып карый башлады. Бик матур, язарга да уңайлы. Тик куанычы озакка бармады. Янәшәсенә сеңелесе Илгизә килеп басты да кычкырып:

— Нинди матур ручка! Кайдан алдың, абый? — дип кычкырды.

Бу көтелмәгән сорауга җавап бирә алмады Рәсим. Алгы бүлмәдән әнисе чыкты. Ул да, улы кулындагы ручканы күреп, шул ук сорауны кабатлады. Рәсим тәмам коелып төште. Җавап бирә алмый, башын аска иеп басып тора. Йөзе кып-кызыл.

— Кеше әйберенә тигәнсең, улым! Кара аны, хуҗасына илтеп бир, — диде әнисе һәм, кисәк кенә борылып, бүлмәдән чыгып китте.

Рәсим ручкага карады, ул элеккечә балкып күренми иде инде.

Икенче көнне Рәсим класска иң беренче булып килеп керде. Керүгә ручканы Илһамның партасына куйды. Озакламый бер-бер артлы сыйныфташлары да килә башлады. Ниһаять, ишектә Илһам да күренде. Ул ручкасын күргәч, балкып, елмаеп җибәрде.

— Онытып калдырганмын икән ич. Югалттым дип уйладым, — дип әйтте ул. — Абыем бүләге.

Рәсим, хуҗасы кулына күчкәннән соң яңадан элеккечә балкып торган ручкага карап, җиңел сулап куйды. (Р.Гыйззәтуллин)

Выполните тесты

1. Рәсим кемнең ручкасына кызыкты?
1) Илһамның
2) Илгизәнең
3) укытучының

2. Ручка нинди?
1) гади
2) сынык
3) бизәкле

3. Рәсим ручканы кайчан ала?
1) дәрес беткәч
2) дәрес вакытында
3) укырга килгәч

4. Рәсим ручканы кая тыга?
1) сумкасына
2) кесәсенә
3) җиңенә

5. Рәсим кулындагы ручканы иң беренче булып кем күрә?
1) сеңелесе

2) әбисе
3) әнисе

6. Рәсимне кем ачулана?
1) әнисе
2) әтисе
3) сеңелесе

7. Икенче көнне Рөстәм мәктәпкә ничәнче булып килә?
1) икенче булып
2) беренче булып
3**)** иң ахырдан

8. Сыйныфка керүгә, Илһам нишли?
1) ручканы Илһамның партасына куя
2) ручканы Илһамның урындыгына куя
3) ручканы яшереп куя

9. Илһамга ручканы кем бүләк иткән?
1) әтисе
2) абыйсы
3) дусты

10. Ручканы күргәч, Илһам нишли?
1) елый
2) елмая
3) ачулана

Прочитайте текст. Озаглавьте.

Учаклар сүндерелгән, палаткалар төреп куелган, кызлар тегендә-монда чәчелеп яткан вак-тояк әйберләрне җыештыралар иде. Алия, табындагы икмәк кисәкләрен газета кәгазенә төреп, үзенең сумкасында буш урын булмаганга, минем букчага тыкты.

— Кош-кортларга салырсың, монда калдырып булмый бит инде, — диде.

Шул вакытта берничә кыз мәш килеп нидер эзли башлады. Диләрәнең абыйсыннан алып торган пәкесен таба алмыйлар икән. Диләрә үзе чак еламый, ашыга-ашыга, әле анда, әле монда килеп төртелә.

Пәке табылмады. Көне буе шау-гөр килеп торган аланлык тынып калды. Походыбыз әнә шулай күңелсез тәмамланды.

Өйгә кайтып, букчаны бушатканда, Алия төреп салган икмәк кисәкләре арасыннан шапылдап авыр саплы пәке килеп төште.

Өс-башымны да алыштырмадым, пәкене эләктереп, Диләрәләргә чаптым. Элек Рүзәлләргә кердем, сөенчене башта аңа әйтергә булдым.

Әмма Рүзәл мине хупламады.

— Син, Сәет, Диләрәгә күрсәтмә инде аны хәзер, — диде. — Букчаңа ялгыш кергәнлеккә ничек ышандырырсың аны...

Мин икеләнеп калдым. Рүзәл — иң якын дустым, миңа зыянга сөйләмәс. Дөрес, кызларда миңа карата шик туса, гаебең юклыгын ничек аңлатырсың? Алия аңлар, кечкенәдән бергә уйнап үскән кыз. Минем букчага үз куллары белән салды бит ризык төргәген. Анысын үзе дә әйтер. Менә Диләрәсе... Бик үткен кыз ул, кимчелегеңне йөзеңә бәреп әйтә. Шамилләр, Әнвәрләр, кешенең тырнак очы кадәр гаебен күрсәләр дә, бөтен дөньяга кычкыралар.

Шулай да пәкене үземдә калдыра алмыйм бит инде.

— Әйдә минем белән, — дидем Рүзәлгә. — Син бит минем кеше әйберенә тимәгәнлегемне беләсең, шикләнсәләр, алатырсың.

Дустым авырсынып кына риза булды.

— Син бара тор, куып җитәрмен, — диде.

Барганда, Алиягә дә кереп әйттем.

Шамил белән Әнвәр кайтканда, Диләрәләр капка төбендә туктаганнар икән.

— Менә, минем әйберләр арасыннан килеп чыкты, — дип, пәкене Диләрәгә суздым. Үзем артымнан килүче Алиягә карадым. Тик ул дәшмәде. Киресенчә, күзләрен миннән яшергән сыман тоелды. Диләрә куанычыннан кычкырып җибәрде. Егетләр дә шатланды, өстәвенә, мине мактый башладылар:

— Рәхмәт, Сәет, әле дә күреп алгансың, югыйсә, абыйсы ачуланыр иде.

Кечкенәдән бергә уйнап үскән Алия генә дәшмәде. Иң якын дустым Рүзәл дә никтер һаман күренмәде. (Л.Гыймадиева)

Выполните задания

1. Кемнең пәкесе югала?
1) Диләрәнең
2) Алиянең
3) Рүзәлнең

2. Пәке нинди?
1) җиңел саплы
2) авыр саплы

3) бизәкле

3. Диләрәгә пәкене кемнән алып торган?
1) дәү әтисеннән
2) әтисеннән
3) абыйсыннан

4. Сәетнең букчасына ризык төргәген кем тыга?
1) Рүзәл
2) Алия
3) Әнвәр

5. Пәкене кем таба?
1) Сәет
2) Әнвәр
3) Рүзәл

6. Сәет сөенечен иң элек кемгә әйтә?
1) Рүзәлгә
2) Алиягә
3) Диләрәгә

7. Сәетнең иң якын дусты кем?
1) Шамил
2) Рүзәл
3**)** Әнвәр

8. Диләрә пәкене күргәч нишләде?
1) куанычыннан кычкырып җибәрде
2) куанычыннан елап җибәрде
3) Сәетне ачуланды

9. Диләрә нинди кыз?
1) оялчан
2) үткен
3) алдакчы

10. Сәет Диләрәгә пәкене биргәч, Алия нишли?
1) шатлана

2) дәшми
3) ачулана

Прочитайте текст. Составь и запиши диалог, используя текст.

Балалык елларымда исемдә калган вакыйгаларның берсе Казанга бару булды. Егерме икенче елның җәендә без әнием белән Казанга киттек. Казан урамнары трамвайлары һәм алма исе белән хәтеремдә калган.

Без Казанда әнием белән Муса Бигиевләргә бардык. Ул унынчы елларда Петербургта мулла булган. Муса Бигиев — Габдулла Тукайның дусты.

Казанда тагын Ибраһим абыйларга бардык. Ул өйләнгән, аларның ике уллары, бер кызлары бар иде.

Прочитайте текст. Составь и запиши диалог, используя текст.

Фәрит тирә-ягын камыш әйләндереп алган күлгә карап утырды да, бала чагын искә төшерде.

Бала чакларында алар күл буена карлыган, шомырт, балан җыярга киләләр иде.

Бервакыт, карлыган җыярга баргач, тау ягыннан кара болыт чыкты. Ул бик тиз килеп җитте. Кинәт кенә яшен яшьнәде, күк күкрәде һәм яңгыр ява башлады. Фәрит бик курыкты, чөнки болын уртасында ул берүзе калган иде.

Аны иптәшләре бик тиз эзләп таптылар һәм тынычландырдылар.

Кара болыт ничек килсә, шулай үтеп китте. Тиздән көн аязды, ялтырап кояш чыкты. Алар, савытларын карлыган белән тутыргач, авылга кайтып киттеләр.

Прочитайте текст. Составьте диалог, используя текст.

Әминәнең мәктәптә укыган вакытта ук нинди дә булса һөнәргә өйрәнәсе килә иде. Шуңа күрә дә ул мәктәпне бетергән елны төзүчеләр әзерли торган училищега укырга керде. Анда штукатур эшенә өйрәнгәч, төзелештә эшли башлады. Төзелешкә килүнең беренче көннәреннән үк яраткан эшенең серләрен тырышып өйрәнергә тотынды. Аның куллары торган саен остарак, җитезрәк хәрәкәт итә башладылар.

Әминә җитмештән артык йорт төзүдә катнашты. Ул эшләгән йортлардагы гажәп яхшы шомартылган стеналар, түшәмнәр, берсеннән-берсе нәфис итеп тартылган кәрнизләр Әминәнең алтын куллы булуы турында сөйлиләр.

Прочитайте текст. Составьте диалог, используя текст.

Очучы Мәгубә Сыртланова санитар эскадрильяда хезмәт итә. Аның сугышның зуррак, җаваплырак, куркынычрак җирендә буласы килә. Шундый

көннәрнең берсендә ул фронт газеталарыннан данлыклы Тамань полкының очучы хатын-кызлары турында укый. Үзен шул Тамань полкына җибәрүләрен сорап, генерал янына бара. Мәгубә Сыртланованы Грозный шәһәре янындагы Кызыл Байраклы Тамань полкына җибәрәләр. Куркусыз татар кызы 782 төнге очыш ясый. Аның сугышчан юлы Берлиннан 80 километр ераклыкта Бруни шәһәре янында тәмамлана. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. (Л. Ихсановадан)

Составь и запиши диалог, используя текст.

Татарның беренче пианисты, танылган композитор, “Тукай маршы” ның авторы З.Яруллин 1888 нче елда Мамадыш районының Кече Сөн авылында дөньяга килгән. Ул бик иртә ятим калган, аның башта әтисе, аннан соң әнисе вафат булган. Заһидулла төрле гаиләләрдә тәрбияләнә. 12 яшендә Чистай шәһәренә килеп чыга, анда музыка кораллары төзәтү остасына эшкә яллана. Шунда ул гармунда уйнарга өйрәнә. Аннан соң Нижгар шәһәрендә гармунчы булып эшли башлый. Заһидулла Яруллин татар музыкасының киләчәк үсешенә көчле йогынты ясаган шәхес. Ул — мәшһүр Салих Сәйдәшевнең дә беренче остазы, танылган композиторлар Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннарның әтиләре.

Составь и запиши диалог, используя текст

Татарстан АССР Ленинградтан эвакуацияләнүчеләрне беренчеләрдән булып кабул итә. Беренче агым республикага сугыш башланганнан соң бер ай узуга, әле блокада башланганчга кадәр үк килә башлый.

1941 нче елның 16 нчы августына кадәр генә дә 162 меңнән артык кеше эвакуацияләнә, шуларның 31 меңе — балалар.

Татарстан халкы ленинградлыларны җылы кабул итә. Аларның күпчелеген халык үз фатирларына, йоритларына сыендыра. Урын җитмәгәннәрен җитештерү цехларына, тиз арада төзелгән баракларга, тулай торакларга урнаштыралар.

Составь и запиши диалог, используя текст

Мең тугыз йөз сиксән алтынчы елның маенда мин Югославиягә бардым. Белградта кунакханәгә урнашкач, кичен бер дустым белән шәһәр карарга чыктык. Урамда халык күп, без белмәгән телдә нәрсәдер сөйләшәләр.

Кунакханәгә кайттык. Бүлмәгә кереп, ял итергә яттык. Кинәт кенә Бөек Ватан сугышында немецларга әсирлеккә төшкән татар солдатлары күз алдына килде. Исән калган әсир солдатларның күбесе туган җирләренә кайтырга курыкканнар, чит илләрдә калганнар. Аларга чит илләрдә тормыш башлап җибәрергә туры килгән. Бик авыр булгандыр аларга. (Р. Кәрами)

Поставьте слова в правильном порядке, восстановите текст.

1) сентябрьдә |Япониядә | башлана |елы | апрельдә | уку | түгел
2) аларда | гына | каникул | ай | җәйге| бер
3) Япониядә| эчендә | белем | алу| 3 | бара | ел| урта
4) бергә |кызлар | дәүләт | ала | мәктәпләрендә| белән| малайлар | белем |
5) ала | читтән | 15 | укый | мәктәптә| торып | укучылар| яшьтән

Поставьте слова в правильном порядке, восстановите текст.

1) янында | тау| Казан | урнашкан | шәһәре | булган | җир
2) бу | Зилант | башында | һәм | патшасы | еланнар | күп | аларның | тау | яшәгән | бик
3) янына | курыкканнар | тау | килергә | кешеләр | бу | якын
4) итәргә| куша | еланнарны | хан | юк

Поставьте слова в правильном порядке, восстановите текст

1) Сабантуй үтте. (күңелле/ бик / Минскида/ быел да)
2) Көн булды. (кояшлы/ бүген/ матур)
3) Мин катнаштым. (төрле/ уеннарда/ күңелле)
4) Дустым ватты. (фин/чүлмәк/белән/ татарлары)
5) Мин тарттым. (кытай/ белән/ аркан/ татарлары)

Поставьте слова в правильном порядке, восстановите текст

1) Бәйрәм уза. (күңелле/ бу/ Австралиядә/ ел саен
2) Мин булдым. (гаиләм/ ял көне/ белән/ Сабантуйда)
3) Без очраттык.(бәйрәмдә/ дусларны)
4) Без аралаштык. (татарча/ рәхәтләнеп/ белән/ алар)
5) Гаиләбез карады. (татарча/ концерт/Сабантуйда)

Поставьте слова в правильном порядке, восстановите текст

1) авыр/ «Дус/ беленер»/ вакытта/ халык/ — ди.
2) яшәү/ түгеллеге/дөньяда/турында/ мөмкин/ дусларсыз/ Психолог/ сөйләде.
3) шатлыкта да, / «Дуслар/ кирәк»/ кайгыда да/ — ди. /
4) һәрвакыт/ дусларга/ яхшы/ карата/ Әти дә/ мөнәсәбәттә/ куша./ булырга
5) дустың/ ышанычлы/булсын!/ — Улым, — ди әби.

АРАДАШ КОНТРОЛЬ ҮТКӘРҮДӘ ФАЙДАЛАНУ ӨЧЕН ТЕКСТЛАР

Дирижерлык таякчыгы

Татарстан Республикасының дәүләт музеенда даһи композиторның хәтта үз исеме белән аталган музеенда да булмаган бик тә кадерле бер ядкарь — аның дирижерлык таякчыгы саклана икән. Салих Сәйдәшевның мемориаль музее ничәмә-ничә тапкырлар гозерләп сораса да, дәүләт музее исә әлеге затлы экспонатыннан аерылырга теләми икән.

Бу яңалык миндә кызыксыну уятты: таякчыкның бер-бер хикмәте булса кирәк. Бәлки ул бик тә затлы, бары тик диңгез арты илләрендә генә үсә торган агачтан эшләнгәндер? Бәлки ул асылташлар белән бизәлгән фил сөягеннәндер?

Юк, диңгез арты илләрендә генә үсә торган агачтан да, асылташлар белән бизәлгән фил сөягеннән дә эшләнмәгән иде ул. Гап-гади, кайрысы кесә пәкесе белән юнылган утыз сантиметр озынлыгындагы бераз кәкрерәк тал чыбыгы иде бу! Скрипка һәм янә дә дистәләгән башка төрле нәзберек, гаярь вә дәртле-моңлы уен кораллары белән идарә итүче даһи кулына килеп эләгәсен каядыр Мишә буенда үскән бу тал чыбыгы чамалады микән?!

...Аны мөгаллимнең күрсәткеч таягына да охшатып була. Менә таяк мәктәптәге иске география картасы буйлап, илләр һәм океаннар аша уза, бөек калаларга килеп төртелә, елга-күлләрне сыйпап үтә. ...Озак кулланудан шомарып беткән әлеге дирижерлык таякчыгына янә текәлдем. Гап-гади тал чыбыгы да даһи кулында тылсымлыга әверелә икән ләбаса! *(180 сүз)*

Һәйкәлләр

Идел ярларыннан алып илебезнең көнбатыш чикләренә кадәр каберлекләр чәчелгән. Дәһшәтле сугыш елларын хәтерләтеп, һәйкәлләр утыра. Азатлык сугышчыларына Европа илләрендә дә һәйкәлләр куелган. Һәркайда — каберлек. Күп алар. Фашистларга каршы соңгы сулышына кадәр сугышкан ил каһарманнары мәңгегә йокыга талган анда.

Сугыш кырларыннан миллионнарча ир-егет әйләнеп кайтмады, күпме аналар үзләренең газиз улларын, күпме балалар кадерле әтиләрен югалтты. Ә бит үлгәннәрнең һәрберсе — үзе бер дөнья, күк гөмбәзендә сүнгән йолдызларны хәтерләтә. Күпләре 20 яшь тә тулмаган яшь егетләр иде.

Каберлекләрдә гүзәл Ватаныбызның бәйсезлеген буарга ябырылган гитлерчыларга каршы көрәштә һәлак булган солдатлар йоклый.

Биек һәм очлы башларына йолдызлар куелган кабер ташлары. Алар — безнең кайгы һәм хәтер билгесе. Сугыш кырларында башын салганнарның алда тормышлары, кояшлы көннәре бар иде. Алар үз гомерләрен — иң зур байлыкларын — матур киләчәк хакына бирделәр.

Җирдә һәйкәлләр тора. Алар гасырлар кичәр. Таш һәм бронза солдатлар, автоматларын нык кысып тотып, мәңгелеккә сакка басканнар. Алар һаман ил сагында. *(165 сүз) (К. Тәхаутдиновтан)*

Батырлык нинди була?

Дәү апасы белән автобуста авылларына кайтып килеше иде Әнвәрнең. Көн кызу, һәммәсе дә әлсерәшеп, йокымсырап утыралар. Кинәт алгы урындыктагы кыз чәчрәп сикереп торды, кычкырып җибәрде хәтта. Янындагы олы яшьтәге бер абый авырып киткән икән. Авып ук төшкән. Пассажирлар югалып калды, ыгы-зыгы башланды. Әнвәр сизмәде дә, дәү апасы кай арада торып киткән дә теге абыйга ашыгыч ярдәм күрсәтә башлаган. Салонга дару исе таралды. Нинаять, киеренкелек бетте, авыру торып утырды. Дәү апасына төрле яклап рәхмәт яудырырга тотындылар. Ул исә, берни булмагандай, янәдән үз урынына килеп утырды. Әнвәр генә шактый озак тынычлана алмый азапланды. Кайтып җиткәнче дәү апасына карыйсы гына килеп торды.

— Син, дәү апа, чын батырлык эшләдең. Юкса синең врач икәнлегеңне монда берәү дә белми иде бит,— диде. Апасы елмайды гына: — Син бигрәк арттырып җибәрәсең инде! — диде.— Батырлык шундый була димени?! Әледән-әле исенә төшеп тора бу хәл Әнвәрнең. «Батырлык идеме?» дип икеләнә. *(140 сүз) (Л. Гыймадиевадан)*

Ашыгудан ни файда?

Әби беркөнне иртәнге сәгать дүрттә үк күрше Сәлим абыйның машинасына утырып районга китте. Кәҗәне көтүгә куарга миңа кушты: «Сәгать челтерәгәч тә торырсың, улым, яме», — дигән булды. Челтерәде будильник. Юрганнан башны да чыгармыйча, кул белән генә мендәр янындагы урындыктан капшана-капшана эзләп таптым аны, төймәсенә басып авызын томаладым. Икенче якка борылдым да тагын йокыга киттем, нигә ашыгырга? Йокыдан сәгать унда гына уяндым. Дөрес, кәҗәм көтүдән калды калуын. Аның каравы үзен кич белән алып кайтасы булмады.

Күрәсезме, ашыкмаудан гел файда! Тик менә каникул гына ашыкты — тиз үтте. Иртәгә Беренче сентябрь икән бит. Шуңа күрә бүген китәм. Казанда әни каршы алырга тиеш. Әнә станция дә күренде инде. Тагын бер чакрым чамасы атлыйсы калгандыр. Чү! Минем поезд килеп туктаган да түгелме соң? Әллә инде кузгалып та бара? Кузгалды шул. Китә бит, китә. Бетте баш. Бүген башка поезд юк бит инде. Их!

Үзем ашыгып атлаган булдым бит әле. Ашыга-ашыга шабыр тиргә баттым. Тик ни файда соң?! Үзегез күреп торасыз — ашыгудан файда юк. *(156 сүз) (В. Нуриевтан)*

Куян

Малай балыкка китте. Җайлырак, тынычрак урынны сайлап йөри торгач, ярдан читтәрәк колакка ниндидер тавыш ишетелде. Барып караса, куак артында яраланган куян ята. Кемдер аңа аткан, тик таба алмаган. Куянның бәхете бар икән. Качып торырга акылы җиткән. Ана куян булырга тиеш, чөнки бәләкәйрәк, ә зуррагы аны саклый.

Ул озынколак янына килде. Куян калтыранды, әмма куркуын җиңде. Ата куян якында гына сикергәләп торды. Алар кем белән эш итүләрен аңлыйлар иде шикелле.

Малай яралы куянны кулына алды, башыннан сыйпады, яралы урынны эзләде. Куян бөтенесенә дә риза булып, тыпырчынмыйча гына ярдәм көтте. Яра аякларында икән һәм шактый тирән.

Малай куянны өенә алып кайтты. Ул аны дәвалады һәм кире таныш куаклар арасына китереп куйды.

Куянның үзен терелткән дустыннан аерыласы килмәде. Ул, байтак вакыт аңа карап, иренен селкеткәләде. Куян нәрсәдер әйтергә теләде. Үзенчә рәхмәт белдергәндер.

Шулай да хушлашырга барыбер кирәк иде. Малай кулын шапылдатып куйды. Озынколак сискәнеп китте, тик аннары, тиз тынычланып, тагын бер урында сикергәләп торды. Шуннан соң куаклыкка кереп югалды. *(174 сүз) (Вакытлы матбугаттан)*

Олимпия уеннары

Олимпия уеннары — 4 ел саен уздырыла торган дөньядагы иң зур спорт ярышлары. Хәзерге вакытта Олимпия уеннары җәйге һәм кышкы уеннардан тора. Алар ике ел саен чиратлашып уздырылалар. Олимпия уеннарында меңнәрчә атлет ярыша. Олимпия чемпионы булу спортчылар өчен иң югары дәрәҗәләрнең берсе.

Олимпия уеннарының тарихы бай. Борынгы Олимпия уеннары Грециядә безнең эрага кадәр 776 нчы елдан безнең эраның 393 нче елына кадәр уздырылган. Безнең заман Олимпия уеннарының беренчесе 1896 нчы елдаАфинада уздырыла. Шулай итеп Олимпия уеннары, тарихы буенча, Борынгы Олимпия уеннарына һәм Хәзерге заман Олимпия уеннарына бүленәләр.

Олимпия Хартиясе олимпия хәрәкәте өчен төп документ. Аның нигезендә Халыкара Олимпия Комитеты эшли.

Олимпия Хартиясе 5 өлештән тора.

Беренче өлеш Олимпия хәрәкәте һәм аның эшчәнлеге турында (статусы, Олимпия символикасы һ.б.).

Икенче өлеш Халыкара Олимпия Комитетына багышланган (Комитетның, Комитет президентының, әгъзәләрең, комиссияләрең статуслары, аларны сайлау тәртибе, рәсми телләр һ.б.) Халыкара Олимпия Комитетының рәсми телләре — инглиз һәм француз телләре.

Өченче өлештә халыкара спорт федерацияләренең Олимпия хәрәкәтендәге рольләре күрсәтелгән.

Дүртенче өлеш Милли Олимпия Комитетлары эшчәнлеге турында (роле, бурычлары, символикасы һ.б.).

Бишенче өлеш Олимпия уеннарына багышланган (уздыру урынын сайлау тәртибе, оештыручыларның җаваплыгы, уздыру тәртибе һ.б.).

Олимпия мәсләге (принцибы): Олимпия уеннарында иң мөһиме җиңү түгел, ә катнашу. Көрәшү җиңеп алудан өстенрәк.

Олимпия факелын Олимпиядә махсус көзге аша кояш нурларыннан кабызалар. Факел ярдәмендә утны узачак Олимпиаданың төп стадионына җиткерәләр. Уеннар ачу тантанасы барышында факел утыннан узачак Олимпиаданың төп стадионында урнашкан махсус кәсәдә ут кабызалар. Ул Уеннар тәмамланганчы яна. *(228 сүз) (Википедиядән)*

Зәңгәр күлдә ай коена

Төннәрен барлык кешеләр йоклап беткәч, бакалар бакылдаудан, кошлар сайраудан, яфраклар шаулаудан, җилләр исүдән туктагач, Зәңгәр күлгә төшеп Ай коена икән. Чөнки ул чисталыкны бик яраткан. Бөтен тәнен исле сабын белән ышкый-ышкый икән дә күлнең иң тирән җиренә чума-чума рәхәтләнә икән. Шулай әллә ничә тапкыр тәнен сабынлап, әллә ничә тапкыр чумып чыкканнан соң ул күп итеп төнбоек чәчәкләре җыярга тотына икән. Чәчәкләрнең дә төрлесен түгел, иң акларын, тәмам ачылып җиткәннәрен генә җыйган ул. Ике учы тулганчы төнбоек чәчәкләре җыйганнан соң, Ай үзенең болыттан ишеп ясаган баскычының йомшак басмаларына сак кына баса-баса күккә күтәрелә икән. Күккә менеп җиткәч, кулындагы төнбоек чәчәкләрен әле бер якка, әле икенче якка ыргытып уйнарга тотына икән. Ә ул ыргыткан төнбоек чәчәкләре күкнең түшәменә кадалып йолдыз булып яна башлыйлар, ди. Әгәр төн уртасында урамга чыгып күккә карасагыз, Айның чәчәкләрне күккә кадап йөрүен күрер идегез, мөгаен. Ул чагында төн көндезге кебек яп-якты була, чөнки яңа гына Зәңгәр күлдә коенып чыккан Айның тәне чипчиста, җилләр йоклагач, болытлар да бүредән курыккан сарык көтүедәй чабышып йөрми, ояларында әкият тыңлап тыныч кына ята бирәләр. Ә Айга рәхәт, ашыкмый гына дөнья гизә, йолдызлар бер-берләренә зөбәрҗәт ташлар ыргытышып уйный башласалар: «Әй, балалар, артыгын шашмагыз. Ыргыткан ташларыгыз җиргә килеп төшәр дә

берәрсен һәлак итәр. Шуннан соң кешеләрнең безгә ачуы чыгар», — дип, йолдызларны тыеп тора икән. *(209 сүз) (Ф. Яруллиннан)*

Көтелмәгән кунак

Безнең солдатлар иртәнге ашны ашап кына бетергәннәр иде. Кинәт югарыда, окоп өстендә, мәче тавышы ишетелде. Бер сержант саклык белән генә торып караган иде, анда кечкенә генә соры песи баласын күреп алды.

Шундый салкын көндә песи баласы килсен, имеш. Әйләнә-тирәдә кара урман. Алда ерак түгел генә бер авыл күренә. Бу авылның өйләре сугышта җимерелеп беткән. Тик ара-тирә җимерек өйләрнең бүрәнәләре генә тырпаеп торалар иде.

Бу авыл фашистлар кулында. Песи баласы, азык эзләп, кешеләр янына килгән булырга кирәк. Әйтерсең ул да ерткыч фашистлардан качкан. Песи баласы, окопка керүгә, кызганыч тавыш белән мияулап җибәрде. Кунакка аш салып бирделәр. Ашагач, аның күзләре матурланып китте, әзрәк уйнады да почмакка барып йокларга ятты.

Песиләр торган җирләрен сагынучан булалар. Әлеге сержант песи баласын алды да окопның кырыена куйды. Песи әзрәк басып карап торды да авылга таба йөгерде.

Икенче көнне иртән песи баласы тагын окопка килде. Бу юлы инде ул мияуламыйча гына окопка үзе сикереп төште һәм тиз генә савыты янына килеп ашый башлады.

Песи баласы безнең солдатларга ияләшеп китте. Көн дә иртә белән килә дә, кичкә кадәр окопта йоклап, тамагын туйдырып, кич белән үзенең туган авылына кайтып китә торган булды.

Сержант, песи баласын авылга озаткан вакытта, һәрвакыт аның аркасына фашист солдатларына мөрәҗәгать итеп язылган бер-ике листовка бәйләп җибәрә торган булды. *(180 сүз) А. Шамов буенча*

Канатлы дусларыбызны онытмыйк

Менә ак тунлы кыш та килеп җитте. Бер-ике көн эчендә әллә никадәр кар яуды. Бөтен тирә-як ак юрган астында калган кебек иде. Кыш җитүгә, урманда кошларга азык табу шактый кыенлашты.

Укытучыбыз Сания апа кошларга җимлекләр ясап куярга һәм анда нинди кошлар очып килүен күзәтергә кушты. Без моңа шатланып риза булдык. Мәктәптән кайткач, һәрберебез җимлек ясарга керештек.

Мин дә тактадан кечкенә генә өстәл һәм җимлек ясадым. Аны урман янындагы карт чыршы төбенә куйдым. Чыршының куе ботаклары җимлектәге азыкны кар басудан сакларлык иде. Җимлек әйбәт булып чыкты. Ул

тәрәзәбездән дә күренеп тора әле. Дөресе шулай. Минем әтием урманчы булып эшли, шуңа күрә без урман эчендәге өйдә яшибез.

Якшәмбе көн иде. Җимлегемә ипи, ярма, кипкән миләшләр салдым. Бер читтән генә карап тора башладым. Менә ике песнәк килеп кунды. Ярма белән икмәкне ашадылар да агач ботагына кундылар. Шул арада кызылтүшләр очып килеп җитте. Минем җимлегемдә алар өчен дә сый бар иде: аларга мин миләш асып куйган идем, рәхәтләнеп миләш чукыдалар канатлы дусларым. Миләш чыпчыгы да авыз итте минем җимлектәге азыктан. Ә чыпчыклар? Алар җимлектән китәргә ашыкмыйлар да әле. Кинәт җимлек өстендәге ботакка тиен сикереп менде. Ул да җимлектә рәхәтләнеп сыйланды.

Хәзер мин көн саен канатлы дусларыма җим бирәм. Кошлар да, тиеннәр дә рәхим итсеннәр. *(200 сүз) (Ш.Бикколдан)*

Кыш көне тауда

Кичә мин тау таптым. Бүген дә шул тауга шуарга барам. Үзем генә барам. Дусларымны көтеп, тау шуарга баруны сузасым килмәде. Мин, гомумән, табигатькә ялгызым чыгарга, ялгызым йөрергә яратам. Әнкәй елмаеп тәрәзәдән карап калды. Күрше Гайнулла бабай да, олы борынын тәрәзәгә төртеп үк, миңа карап калды.

Мин ераккa китеп шуам, юлның теге ягына. Ә-нә теге җиргә хәтле барам. Кичә дә шунда барган идем. Шунда мин үземә яхшы тау таптым. Чаңгым да яхшы. Тирә-якта кар ап-ак, тирән. Ак кар өстендә бик күп эзләр бар. Менә монда төлке, бүре эзләре. Эзләренә караганда пошилар да азык эзләп авыл янына килгәннәр. Ә куян эзләре исәпсез-хисапсыз. Кар өстендәге эзләр буенча хикәя язарга мөмкин икән бит. Бүген көн салкын. Җил дә юк. Бөтен җир ап-ак! Өченче көн инде шулай. Мондый көннәрне мин санап барам. Кинәт җайлап кына кар ява башлады. Кар яуса, көн җылыта, дигән иде әти. Җылытыр, ахрысы.

Монда җәй көне нинди җылы иде! Чәчәкләр бар иде. Ак, зәңгәр, сары, ал чәчәкләр... Күбәләкләр! Мин ак күбәләкләрне яратам. Кар бөртеге, ак булса да, күбәләк була алмый. Кыш көне күбәләк кар була, боз була...

Салкын булуга карамастан, минем кулларым өшеми. Чөнки минем җылы бияләйләрем бар. Бик җылылар, җылы булмаска, аларны миңа әнием бәйләде бит. *(187 сүз) (Р. Фәиздән)*

Айдар

Бу ятимнәр йортында әнисез яки әтисез балалар күп. Әтисез-әнисез балалар да бар. Кайберләренең әти-әнисе генә түгел, әби-бабасы, туган-тумачасы да юк. Анысы гына нәрсә... Айдарның туган көне дә юк хәтта. Барлыкка бар, тик дүрт елга бер генә килә. 29 нчы февраль көнне туган шул ул, кәбисә елны.

Шуңа күрә, бер мәртәбә үткәрә дә, өч ел рәттән туган көнсез, бәйрәмсез яши. Бу балалар йортына килгәч, ул әле бер дә үткәрмәде туган көнен.

Ә ятимнәргә туган көн бик кирәк. Туган көннәрен билгеләүче балаларга бу көнне тәмле ризыклар бирәләр, яңа киемнәр кидерәләр, алар янына туганнарын, дусларын чакыралар... Иң мөһиме: бу көнне аларны кыйнамыйлар. Хәтта иң усаллардан саналган Хәмис тә андыйларга кул күтәрми. Шундый тәртип.

Кызганыч,быел да 28 февральдән соң 1 март килде. Быел да Айдар туган көнсез калды. Иртән торуга ук, түшәгенә капланып, елап алды. Юк, беркемгә дә рәнҗеп яисә үпкәләп еламады ул.. Бүген тагын кыйналасын белеп, шул кыйналган вакытта еламас өчен елады. Чөнки белә: алдан елап, күз яшьләреңне түгеп, күңелеңне бушатып куйсаң, соңыннан, ничек кенә кыен, авыр булса да, еламый калырга мөмкин. Артык горур шул ул. Хәмис аны күпме үз янына алырга, үзенә йомышчы итәргә тырышып карады. Айдар барыбер баш бирмәде, кыйналса — кыйналды, әмма Хәмиснең куштаны булмады. *(198 сүз)* (*Г. Гыйльманов буенча)*

Маһия әби

Автобус тигез юлдан, тузан туздырып, алга чаба. Кинәт юл читендә чандыр гына бер карчык күренде. Ул кәшимир яулык бәйләгән, ә өстендә кызыл бәрхеттән тегелгән камзул белән күлмәк, аягында бизәкле читек иде. Менә ул таягын өскә күтәрде. Шофёр егет автобусны шунда ук туктатты. Әби, рәхмәт укый-укый, минем яндагы буш урынга килеп утырды. Итәкләрен рәтләп, якягына каранып алды.

Әби сүзгә бик оста булып чыкты. Пассажирлар белән бик тиз элемтәгә керде. Арткы урында утырып барган чуваш агае белән чувашча сөйләшә башлады, икенче берәүнең русча биргән соравына да шома гына русча җавап кайтарды. Мин түзмәдем, сорап куйдым:

- Әби, син ничә тел беләсең соң?

- Ничә тел дип инде, балам... — Маһи әби, яулыгын төзәткәли-төзәткәли, бармакларын бөгап санап китте:

— Татарча — монысын үз телем булганга, чувашча — күршеләр теле, русча белмәү гөнаһ инде, балам. Шуларга кушып, гарәпчә дә укыштырам. Әле Казахстан якларыннан кайтам. Сеңлем яши анда. Шунда казахлар белән дә рәхәтләнеп аралаштым. Тел бик кадерле нәрсә, телләр белү зур хәзинә ул,балам. Юкка гына халык: “Телләр белгән — дөнья гизгән,” — димәгән. Тик кешеләр шул тел белән бер-берсен рәнҗетеп кенә ялгышалар. *(176 сүз) (Г.Сабитовтан)*

Шомырт нигә елый?

Зәй буендагы ул ялгыз шомырт төбенә палаткабызны корып куеп, бер җәйне бик күнелле ял иткән идек без. Мин кармак салып утырам, улым аланда

чикерткәләр куа, зәңгәр-кызыл тубын чөеп уйны, тал-тирәк куаклары арасында сайрашучы кошлар белән нидер сөйләшә, уйный-уйный аргач, шомыртның куе рәхәт күләгәсенә ятып йоклап та ала.

Шул көннән бирле шомырт якын дустыбызга әйләнде һәм без улым белән һәр язны шомыртыбызның хәлен белергә бара торган булдык. Шомырт безне бик куанып каршылый, бөреләрен яңа гына ачып чыккан нәни-нәни яфраклы кул-ботакларын изәп, безне сәламли.

Аннары без шомыртыбыз янына шау чәчәккә төренер чакларын чамалап киләбез. Бу вакытта әле чияләр, алмагачлар, миләшләр, язгы җилләргә горур гына баш игәләп, үзләренең чәчәк бөреләрен ачар-ачмас кына утыралар. Бу дөньяда үзләре генә белә торган тантана көннәрен көтәләр алар.

Җәй азакларына таба да без шомыртыбызга кунакка киләбез. Дустыбыз безне, авызны бераз бөрештерсә дә, ифрат тәмле чем-кара җимешләре белән сыйлый.

Быел шомыртыбызның яфрак ярган шатлыгын уртаклашырга, ничектер, бара алмый калдык. Шунлыктан аның мул чәчәкле, хуш исле бәйрәменә вакытында барып җитәргә ашыктык.

Шатлыгын уртаклашырга дип килсәк тә, шомыртның бик моңаеп, боегып утырганын күрдек. Дустыбызның бәйрәменә соңга калдыкмы икәнни? Әнә бит, инде чәчәк тажларын коеп-сибеп тә бетерә язган ул, иң очтагы ботакларында гына берән-сәрән ак тәлгәшләр күренә.

Килеп җитүгә, дустыбыз каршында башларыбызны иеп, сүзсез басып калдык. Юк, чәчәкләрен коймаган шомырт, аны талаганнар. Ботагы-ботагы белән сындырып алып, кул җитәрдәй бөтен чәчәкләрен урлап киткәннәр. Кул җитәрдәй урлар чәчәк калмагач, кайсыдыр тагын да өскәрәк үрмәләгән һәм шомыртның бер канатын сындырып ук төшергән. Ул каерылган канат-ботак җиргә үк салынып төшкән, яфраклары, әрнеп, йөзләрен җыерганнар. Тал-тирәк арасында ниндидер кошлар моңсу гына сайрашып куя, бөтен Зәй буе моңсуланып, шыксызлынып калган иде. Акрын гына шомыртыбыз янына атладык.

- Шомырт... елый, — диде улым, агачның һәр ботагында җемелдәгән тамчыларга карап, үзенең дә күзләреннән мөлдерәп чыккан күз яшьләрен кул аркасы белән сөрткәләп алды.

Әйе, елый иде шомырт... (*330 сүз) (Р. Төхвәтуллиннан)*

Равил гаебен таныды

Равил, мәктәптән кайткач,ашады, эчте дә, тимераякларын алып, урамга чыгып китте.Ул кузгалып китәргә торган автобус артына тотынып барырга теләде. Автобус кузгалды. Алдагы тукталышка җитәр алдыннан, Равил кулла-

рын ычкындырды һәм юлның икенче ягына чыкты. Ләкин каршыга килә торган йөк машинасын ул күрмәде.

Кинәт кенә машина алдына килеп чыккан баланы күргәч, тәжрибәле шофёр да каушады.Зур тизлек белән килгән машинаны туктатырга соң иде. Шофёр гәүдәсе белән рульгә ятты һәм машинаны тротуарга борды. Машина баганага бәрелде һәм туктап калды.Ә Равил алдына-артына карамыйча йөгерде.

Икенче көнне Равилнең күңеле тыныч, кәефе яхшы иде. Кичә булган хәлне ул исенә дә төшермәде. Әйтерсең, бернәрсә дә булмаган!

Зур тәнәфес вакытында Равил коридорда сыйныфташлары янына килде. “Хәзер әтине эшеннән чыгаралар”, — диде Сәлим, күңелсез генә. “Нәрсә булды? Ни өчен?” — дип сорады Равил. Аңа кичәге вакыйганы сөйләп бирделәр.

Равил бик борчылды, аның Сәлимнең әтисенә ярдәм итәсе килде. Иртән торгач, ул Сәлимнең әтисе эшли торган җиргә барды. Директор кабинетына керде, аның белән исәнләште дә: “Барый абый Сөләймановны эшеннән чыгармагыз, директор абый. Ул гаепле түгел!” — диде. “Ничек гаепле түгел? Ул бит машинаны ватты!” — диде директор. “Минем аркада ул,” — диде Равил һәм барысын да сөйләде.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Директор Сөләймановны чакыртты, машинага ремонт ясарга кушты. Сәлимнең әтисе эшендә калды. *(204 сүз) (Ә.Дибаевтан)*

Менә кем иде ул Алиш

Кем соң ул Алиш?

Абдулла Алиш балаларны бик яраткан, алар өчен әкиятләр, шигырьләр, кечкенә хикәяләр язган, ләкин явыз сугыш аның гөрләп торган эшләрен бүлә. Меңләгән кешеләр белән бергә Алиш сугышка китә.

Абдулла Алиш туган илен бик ярата, ул чын патриот була. Яраткан язучыбыз Аркадий Гайдар кебек, кулына корал тотып, Ватанны фашистлардан саклый. Ул бик батыр солдат була, бернәрсәдән дә курыкмый. Каты яраланып, 1941 нче елның октябрендә Дёсна елгасы буенда дошман кулына төшкәч тә, ул аңа баш иярге уйламый. Аны Алитус лагерена ябалар, аннары Чехословакиягә, Германиягә озаталар. Алиш, тугрылыклы иптәшләре белән бергә, качу турында хыяллана, ләкин алар кача алмыйлар, серләре ачыла. Шуннан соң аларны бик каты газаплыйлар, ашарларына берни дә бирмиләр.

Лагерьларның берсендә Алиш Муса Җәлилне очрата. Алар бер-берсен элек-электән яхшы беләләр, икесенең дә йөрәгендә фашистларга карата нәфрәт уты яна. Алар соңгы сулышларына кадәр көрәшергә ант итәләр. Дуслар бергәләп листовкалар язалар. Фашистлар хәрби әсирләрдән легионнар төзи башлагач, әсирләргә фашистлар сүзенә ышанырга ярамавын, илгә хыянәт итү — иң зур җинаять икәнен аңлаталар. Аларның агитацияләре уңышлы була. Ле-

гионерлар, фронтка җибәрелгәч, үзләренең немец командирларын үтереп, партизаннар ягына чыгалар.

Шуннан соң гитлерчылар шикләнә башлыйлар. Ниндидер бер сатлык җан аларга яшерен оешма турында әйтә. Муса Җәлил, Абдулла Алиш һәм аларның якын дуслары, кулга алынып, Моабит төрмәсенә ябылалар. Биредә аларны тагын бик каты газаплыйлар, ләкин алар дошманнан шәфкать сорамыйлар, батырларча һәлак булалар. *(226 сүз) (Г. Әпсәләмовтан)*

Чишмә

Зөфәр балачактан урманда йөрергә, кошлар сайраганны тыңларга ярата. Менә бүген дә иртән торуга, тиз генә киенде дә урманга китте ул. Урман эчләп бара торгач, Зөфәр бер тау буена килеп чыкты. Тауны чыршы, нарат, шомырт агачлары каплаган. Таудан да гаҗәбрәге алда икән.

— Чишмә! — дип кычкырганын сизми дә калды Зөфәр.

Җырларда макталган, әкиятләрдә тылсым иясе булып гәүдәләнгән чишмә. Үз урманнарында чишмә барын Зөфәр моңарчы ничек белми йөрде икән? Әнә ул ярга сыенган ташлар арасыннан, агач тамырлары өстеннән, җырлый-җырлый, түбәнгә сикерә. Кайдан килә ул, кем аңа юл ачып җибәргән?

Зөфәр табигатьнең оста кулы озак еллар буе шомартып ясаган ак таш урындыкка килеп утырды. Савытын алып, чишмә суын тутырды. Салкынлыгы тешеңне сындырыр. Бу эсседә күп эчәргә ярамый. Зөфәр тирләгән битен, башын боздай салкын су белән юды да чишмә кырыендагы әле яшеллеге бетмәгән, үзенә бер тәмле ис аңкып торган үләнгә сузылып ятты. Табигате бигрәк матур һәм бай шул туган илебезең!

Чишмә. Сусап, арып барган юлыңда чишмә очраса — нинди бәхет. Чыннан да тылсым иясе ул. Сиңа көч, куәт биреп җибәрә. Аннан соң озак еллар буена шул чишмәне сагынып сөйлисең. Ә менә бу чишмә? Ул күпме кешенең юлында очраган, кемнең сусавын кайтарган, кемнең ярасын юган, кем белән ерак юл үткән? Бәхетлеме бу чишмә? Ераста калган бәхетен сагынамы? Яки алдамы әле аның бәхете?

Чишмә бу турыда сөйлидер, бәлки җырлыйдыр. Аның телен аңлап булмый шул.

Шулай да үзеңнең чишмәңне табу — зур шатлык. *(220 сүз) (Г. Нәбиуллиннан)*

Укытучым

Менә көз җитте. Укулар башланды.

Безне яклар өчен сәер яңгырашлы Демченко фамилияле апа безнең мәктәптә рус теле укыта башлады. Аны барысы да бик яраттылар.

Аның ире очучы икән. Ул сугышта. Ә Анна Сергеевна гомердә күз алдына китермәгән татар авылында балалар укыта. Аңа бик еш хатлар килә. Андый көннәрдә ул бик шат күренә. Ә кайчакта уйчанланып китә. Кич улы белән урамда йөри, чишмә буйларына төшә.

Уку елы тәмамланды. Берничә көн узгач, авылга авыр хәбәр килде: Петяның әтисе һава сугышыннан соң кире кайтмаган. Бу хәбәрдән соң апа бер атна авырып ятты, төсе качты. Ә беркөнне минем укытучы апам кинәт юкка чыкты. Аның кая киткәнен беркем дә белми калды.

Күп еллар үтте. Анна Сергеевна укыткан балалар, үсеп, күптән инде төрле өлкәләрдә илебезгә хезмәт итәләр. Ләкин күңел түренә кереп урнашкан укытучыны беребез дә онытмады. Соңгы көннәрдә үзәк газеталарның берсендә басылган искиткеч бер хәбәр кадерле укытучымны тагын күз алдына китереп бастырды.

Белоруссия сазлыкарын киптереп, трактор белән сөргән вакытта, самолет калдыклары табылган. Тимер-томыр арасыннан очучының сөякләре килеп чыккан. Көмеш портсигарында исем-фамилиясе сакланган икән. Игенчеләр якындагы хәрби бүлеккә хәбәр итәләр. Ватан сугышында геройларча һәлак булган очучыны кадерләп күмәләр, портсигарда язылган исеме буенча, кабер өстенә “Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган очучы А.М. Демченко” дип язып куялар. Шул ук вакытта газетада, очучының Ватан сугышында күрсәткән батырлыгын искә алып, хөкүмәт тарафыннан аңа, үлгәннән соң, Герой исеме бирү турында хәбәр ителә. Геройның Анна Сергеевнаның ире булуы турында һич шик юк иде. Бу хәбәр яшен тизлеге белән бөтен авылга таралды. *(224 сүз) (Г. Бакирдан)*

Урманда

Бүген алар урманга барырга уйладылар. Күбесенең туган көннәре бер тирәдә. Гөлнараларның сыйныфы унбиш яшьләре тулганны билгеләп үтәргә булды. Соңгы уку елында матур хатирәләр калсын әле.

Алар урманга килеп җиткәндә, кояш шактый күтәрелгән иде инде. Агачлар тагын да яшәреп киткәндәй тоелды. Чәчәкләр дә көндәгегә караганда матуррак!

Тирә-якка соклана-соклана сукмактан кереп барганда, Гөлнара кычкырып җибәрде: «Ә без бит әле урманнан рөхсәт сорамаган!» Бу сүзләрдән кайсы көлде, ә кайберләре тезелешеп басып: «Урман бабай, керергә мөмкинме? Мөмкин булса, бер кошыңны сайратчы», — диде. Шулчак, чыннан да, бер кошчык бик моңлы итеп сайрап җибәрде.

Сыйныфташлары уйнаганда да, бәрәңге пешергәндә дә, ул эшчән кырмыскаларны карап, урман докторы тукранның тавышын тыңлап йөрде. Та-

бигать барысын да аңлый, ә дус егетләре, кызлары ни өчен аңламыйлар соң аны?

Сәеррәк шул ул: башкалар кочак-кочак чәчәк җыйганда да Гөлнара бернинчәне генә өзә; иптәшләре агач ботагын сындырганда да үзенең кулларында авырту сизгәндәй була.

«Аерылып йөрү килешмәс», — дип, Гөлнара дуслары янына килде. Сөйләшеп, көлешеп утыргач, кәефе дә күтәрелеп китте. Кайтыр вакыт җитте. Алар җыена башладылар. Гөлнара консерв банкаларын, кәгазь кисәкләрен җыярга тотынды. Бер-ике иптәше дә аңа килеп кушылды. Урманны пычратып калдырырга ярамас! Кайбер сыйныфташлары: «Җыегыз, җый!» — дип көлештеләр. Әмма ул бер сүз дә дәшмәде, йөрәге әрнеп уйлады гына: «Юк, аңламыйлар мине. Әнә тукран да агачларны кортлардан коткара, кырмыскалар да урманы чистарта. Ә без?» *(213 сүз.) (Ф.Бәдретдиновадан)*

Табигатькә сәяхәт

Урманга килеп кергәч, һаваның сафлыгыннан хәтта баш әйләнеп киткәндәй булды.

Гафур бабай, бераз машина йөргән юлдан барганнан соң, малайларны җәяүлеләр юлыннан алып китте. Инде кояш та агачлар арасыннан күренә башлаган иде. Бераздан юл бормалы тар сукмакка әйләнде. Аның буйлап бара торгач, аланлыклар күренә башлады.

— Килеп җитәбез, ахры, — диде Кәрим, олыларчарак итеп.

— Әйе, — диде Дамир, — әнә нинди җиләклекләр китте!

Барып җитәргә иртәрәк икән әле. Гафур бабай, кырт кына борылып, малайларны уңга алып кереп китте. Бусы инде алар өчен махсус югалту белән бер иде. Шуңадыр, мөгаен, иптәшләреннән күбрәк белгән Кәрим дә:

— Кире авылга кайтып, юлдан яңадан килергә кушсалар, мин тар сукмакка кадәр генә килә белер идем, — дип, үзенең юл югалтканын танырга мәҗбүр булды.

— Аңа кадәр мин дә килә алыр идем, — диде Дамир, сер бирәсе килмичә.

— Һай, болай булгач, сезгә ышанып ерак китәрлек түгел икән әле, дип кеткелдәде аларның сүзенә колак салып барган Гафур бабай. — Күз алдыгызда торган урманга кереп, өч-дүрт чакырым да үтмәдек, юл югалтып, бутала, адаша да башладыгыз. Ә бит бернинди ориентир приборлары алмыйча, хәтта тайганы гизеп йөрүчеләр бар!

Гафур бабай моны шаяртып кына әйтте, билгеле. Ул белә, урманда ерак китеп йөргәне булмаган малайларга әледән-әле алышынып торган юллар белән сукмакларны хәтергә салып бетерү мөмкин түгел иде. Шуңа күрә дә алар аның

сүзләреннән соң, чиксез океаннар, калын урманнар һәм миражлы чүлләрне гизеп йөрүче кыю кешеләрне күз алдына китереп, бер мәлгә уйга калдылар.

Мондый матурлыкны күрмичә үсүче шәһәр малае Таһиржанга урман аеруча серле, могҗизалы булып күренде. Ул үзен икенче дөньяга эләккәндәй хис итеп, монда күргәннәрнең бөтенесен хәтеренә сеңдереп барырга тырышты. *(220 сүз) (Зәһит Фәйзидән)*

Елга буенда

Таһиржан эшлисе эшләрен бетерүгә, алдагы көн өчен уку әсбапларын карап-әзерләп куйды да, иң яраткан җиренә — Казансу буена китте.

Бүгенге Казансу аны аеруча тарта иде. Ул, бөтен көч-гайрәтен күрсәтергә теләгәндәй, ярларыннан тулып ашкан.

Таһиржан, кызу-кызу атлап, елга буена бара. Елгага якылашкан саен, аңа рәхәтрәк тоела, җанына ниндидер җиңеллек бөркелә бара иде.

Ул су буена тезелгән таллар янына килеп җиткәч, тукталып, тынып калды. Җылымса җил шундый ягымлы, ләззәтеннән күзләре йомыла. Әйтерсең, аның битен әнисенең йомшак кулы иркәли! Таһиржан, калкурак җиргә басып, ургыл агымны күзәтә башлады.

Казансу ярларыннан ашып, әллә нинди куркыныч чоңгыллар ясап агучы ташкынга әйләнгән. Аның, болганып, кызыл-кучкыллы булган суында йә көтүе-көтүе белән, йә берән-сәрән булып эреле-ваклы бозлар, агач кисәкләре, ташландык әрҗәләр һәм санап бетергесез күптөрле чүп-чар агып бара. Соңгылары чисталыкка битараф, бер-берсенә хөрмәтсез һәм культурасыз бәндәләргә ләгънәт укып үтәләр әйтерсең. Язгы агымнар бу күңел кайтаргыч чүп-чар һәм ташландык әйберләрне агызып алып китсә дә, алар, кая да булса башка җиргә барып, андагы матурлыкны, андагы тормыш ямен киметәчәкләр.

Төркемләшеп агып барган бозлар, урыны-урыны белән кызулап китеп, берсен-берсе куып җиткәндә, бәрелешеп, пыяла кебек чәлпәрәмә киләләр. Икенчеләре дә, чоңгыллы бөтеремгә җиткәч, бәрелешеп, таркала. Тик берсе генә дә үзеннән алдагыларны кабатламый. Һәркайсы үзенчәрәк агып килә һәм үзенчәрәк таркалып юкка чыга. “ Ә бит кешеләр тормышы, кешеләр язмышы да шулай, — дип куйды агымга карап уйга калган Таһиржан. *(208 сүз) (Зәһит Фәйзидән)*

Талантлы композитор — Салих Сәйдәшев

Татар музыка сәнгатенең иң күренекле вәкиле, татар профессиональ музыкасына нигез салучы талантлы композиторыбыз Салих Сәйдәшев 1900 елның 3 декабрендә Казанда туа. Әтисе улы туарга 15 көн кала дөнья куя. Әнисе Мәхүпҗамал апа шәфкатьле, ярдәмчел, хөрмәтле кеше була.

Салихның тормышында якты, тирән эз калдырган, композиторның беренче терәге, зур ярдәм күрсәткән кеше — җизнәсе Шиһап Әхмәров була.

Әминә апасы белән тормыш коргач, җизнәсе аны үзенә тәрбиягә ала. Аның музыка белән кызыксынуын күреп, Салихның сәләтен үстерү өчен, уңайлы шартлар тудыра, бар көчен куя.

Сәйдәш музыкасының әһәмияте, кыйммәте көннән-көн, елдан-ел арта бара. Ул халыкка 400 дән артык җыр, романс, увертюралар, маршлар бүләк итә. Шул исәптән, 40 ка якын сәхнә әсәренә музыка яза.

Музыкасы белән генә түгел, шәхес буларак та Сәйдәшев халык арасында ифрат популяр кеше булган. Кешеләр белән ул бик теләп аралашкан, мохтаҗларга ярдәм итәргә һәрвакыт әзер торган. Зур популярлыгына карамастан, иптәшләре арасында үзен гаҗәп дәрәҗәдә тыйнак тоткан. Замандашлары күңелендә ул урта буйлы, очкын чәчеп торган зәңгәр күзле, гаҗәеп ягымлы, җитез, йомшак табигатьле кеше булып сакланган.

Әдәбиятта без иң беренче Тукай дисәк, музыкада иң беренче Сәйдәш исемен әйтәбез.

Сәйдәш моңнары... Бу сүзләрдә никадәр тирән мәгънә, туган җиргә, туган якка булган никадәр мәхәббәт, никадәр тылсымлы, серле көч ята. Татар музыка сәнгатен үстерүдә Салих Сәйдәшевнең өлеше чиксез зур. *(200 сүз) (Вакытлы матбугаттан)*

Мин кулыма китап алам

Без — китаплы халык. Бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән кулъязма китаплар шул хакта сөйли. Кулъязмаларны күчереп язучы осталар барлыкка килгән. Халык арасында шуңа күрә кулдан язылган китаплар күп булган. Әле хәзерге көнгә кадәр галимнәр кулъязма китапларны табып торалар.

Аннан басма китаплар чоры башланган. Хәтта Италиядә дә Шәрык илләрендә чыккан китаплар киң таралган. Ләкин алар гарәп һәм фарсы телләрендә булган. Безнең әби-бабайларыбыз үз телләрендә белем алганнар, шул ук вакытта фарсыча да, гарәпчә дә белгәннәр, шуңа күрә ул китапларны укый алганнар. Шунысы мөһим: без үзебез генә белемле булып калмаганбыз, мәгърифәт нурларын башка тугандаш халыкларга да таратканбыз.

Яңа чорлар килде. Радио-телевидение, компьютер, интернет заманы. Техника, электроника үзгәрә, компьютерлар, телефоннар, телевизорлар яңара, камилләшә. Уены да шунда, дәреслекләре дә, фильмнары да, музыкасы да, фотосурәте дә — барысы да... Фәнни-техник прогресс, һичшиксез, уңай күренеш.

Тик классикларыбызны укып үсмәгән, бүгенге язучыларыбызны белмәгән милләтттәшләребез рухи тамырларыбызны да, тарихыбызны да, гореф-гадәтләребезне дә аңламаслар дигән шигем бар.

Без күп гасырлар дәвамында белемне бары тик китап аша алганбыз. Дөнья цивилизациясенең казанышларын да, халкыбызның бай тарихын да, рух ныклыгын да безгә китап биргән. Шуңа күрә дә без Китапка чиксез рәхмәтле.

Бүгенге көндә безнең төп рухи таянычыбыз китап булырга тиеш! Китапсыз күңел — буш күңел, китапсыз йорт — нурсыз йорт, китапсыз милләт — киләчәксез милләт. Бәхетебезгә, без андыйлар түгел! Әлегә...(*199 сүз) (Р.Миңнуллин буенча)*

Рәмзиянең әбисе

Рәмзия әбисенә чәй әзерләргә булышты. Ак чәйнектән чынаякларга чәй агызгач, өйгә тәмле ис таралды. Шушы эшләр арасында Рәмзия әбисенең яшь чагын күз алдына китерергә тырышты. Ләкин ул аны берничек тә яшь, таза, җитез итеп күз алдына китерә алмады. Ул һаман шулай кечкенә, ябык, гап-гади бер карчык булгандыр кебек иде.

— Әби, синең яшь чактагы рәсемең юкмы? — диде ул, әбисенең яшь чагын күрәсе килеп.

— Бар, ник булмасын, — диде карчык. Карчык комод тартмасын ачты да төргәктән зур гына бер рәсемне алып, оныгына күрсәтте.

— Әбиеңне табасыңмы менә шуннан? — диде.

Рәсемдә бер төркем хатын-кызлар иде. Күбесе — яшьләр. Өчпочмаклы яулык бәйләгәннәр. Яулыксызлары да бар. Рәмзиягә әбисе моннан 50 еллар элек булган очрашу турында сөйләде, хәтта рәсемне ни өчен эзләп табуын да онытты.

— Әбием, син бит әле үзеңне күрсәтмәдең, — дигәч кенә, бер япь-яшь кызга күрсәтте.

Ачык якалы блузка кигән, билен каеш белән буып, иңбашыннан нәзек каеш җибәргән, кыска чәчле, түгәрәк ягымлы йөзле, зур кара күзле кызны ул, үзенең әбисе дип, беркайчан да әйтә алмас иде.

Ул көнне Рәмзиягә әбисе бик күп истәлекләр сөйләде. Алар мактау кәгазьләрен карадылар, сакланган хатларны укыдылар. Аларда әбисенең яшьлеге генә түгел, аңа таныш булмаган бөтенләй яңа бер тормышның истәлекләре икәнен аңлады ул. Аның әбисе, һәҗәр карчык, бу тормышта бик кирәкле, бик кадерле кеше булган икән бит. *(200 сүз) (Л. Ихсановадан)*

Күңел күзе

Ландышлар чәчәк аткан вакытта, Камил әтисе белән урманга барды. Әтисе юлда аңа: “Урман ул — зур, серле, күңел күзе белән карасаң гына, бөтен нәрсәне күрерсең”, диде. Камил көлеп җибәрде: “Кешенең күзе маңгаенда гына була, күңелнең күзе булмый, шаяртасың”, — диде. Әтисе каршы килмәде.

“Шулай, тик күңел күзе белән карамасаң, маңгай күзе берни күрми ул. Шуңа күрә борынгылар, маңгай күзе — ботак тишеге, дигәннәр”, — диде.

Урман аларны тын гына каршылады. Биек-биек наратлар селкенми дә утыралар. Камил өскә карады. Агач башлары сизелер-сизелмәс кенә селкенәләр, әйтерсең үзара нәрсә турындадыр сөйләшәләр.

Шулчак бер нәни кошчык, Камилләр янындагы ботакка кунып, ярсып чыркылдарга тотынды. Камил белән әтисе, тын да алмыйча, кошны күзәттеләр. Ачулы кош аскы ботакка төшеп кунды һәм тагын да усалрак итеп чыркылдарга тотынды. Камилнең әтисе көлемсерәп куйды:

— Бу кош безгә моннан китәргә куша бит әле, ачулана. Бәлки, бу агачта аның оясы бардыр...

Камил, ашыгып, әтисенең сүзен бүлде:

— Оясында балалары бардыр. Әнә әти кош балаларына җим алып кайткан.

Камилләр башка агач төбенә күчеп утырдылар. Кошларга шул гына кирәк иде дә, шунда ук тынычландылар. Камил аларның ояларын күрергә теләп караса да күрә алмады. Кайтыр юлга чыккач, моны ул әтисенә әйтте. Әтисе аны юатты, аркасыннан сөйде.

— Аның каравы, урманны күңел күзе белән кararга өйрәндең. Ә кош оясын күрергә кирәкми дә, — диде. *(200 сүз) (Р.Хафизовадан)*

Язмышлар

Без кем һәм кайдан? Нинди язмышлар йөртә безне читләрдә?

Әтине бала чагында, 1917 нче елгы Октябрь революциясеннән соң берничә ел үткәч, әнисе һәм үзеннән кечерәк өч сеңлесе белән ерак Кытайга алып китәләр. Алар чыгышлары белән Пенза өлкәсенең Нопар авылыннан. Туган яклардан аерылу ачысы, авыр һәм михнәтле юллар, катлаулы, озакка сузылган сәяхәт. Мәрхүм әбиемнең батырлыгын, тәвәккәллеген ничек аңлатырсың да, аңа ничек сокланмассың? Үзенең туган теле булган татар теленнән башка тел белмәгән авыл хатыны, берсеннән-берсе кечкенә дүрт сабый баласын алып, меңнәрчә чакырымлык юлга чыга. Бар байлыгы бер чемоданга сыеп беткән аның, ләкин самовары булган. Алар Благовещенск каласыннан Кытайга үтәләр. Яңа тормыш кору кайда да җиңел булмый, билгеле. Әмма татарга хас тырышлык ярдәм итә аларга. Җиң сызганып эшлиләр, җиңелме — авырмы дип тормыйлар. Татарлар берләшә башлый. Үзләренә җәмгыять төзергә, мәчет салырга, мәктәп ачарга ниятлиләр. Һәркем кулыннан килгән кадәр ярдәм итә. Шулай итеп, татар мәдәниятенең һәм ислам учагының нигезләре салына башлый Кытайда.

Әниeм дә шул ук Пенза якларыннан. Революция дәһшәте, гражданнар сугышы аның гаиләсен дә туздыра. Әниемне абыйсы Харбин якларына җибәрә. Менә шулай язмыш әтием белән әниемне ерак Кытайда кавыштыра. Алар гаилә корып җибәрәләр, бик матур, күпләргә үрнәк булырлык итеп яшиләр алар. Ләкин 1945 нче елда әтиемне бер гаепсезгә кулга алалар һәм әниeм, өч баласын алып, мең бәла белән Төркиягә китеп урнаша. Аңа анда да тормышны өр-яңадан башлап җибәрергә кирәк була. Әтием безнең янга егерме елдан соң гына кайтты.

Әйе, язмыш катлаулы, ә без — язмыш балалары. *(200 сүз) (Ф. Идeлледән)*

Институттан куылу

Ул көнне, социаль чыгышы шикле затның баласы буларак, институттан куылып кайтып кергәндә, әни өйдә иде. Дәфтәр тикшереп утыра. Ул — укытучы. 18 нче татар мәктәбендә башлангыч класс балаларын укыта. Үзе дә, читтән торып, педагогия институтында укый. Күрәсең, минем хәсрәтем йөземә бәреп чыккан булгандыр, әниeм, шунда ук эшеннән аерылып, сорау белән миңа текәлде. Бер мизгел тынлык булып торды. Әниeм тиз генә үзен кулга алды, мөмкин кадәр тыныч тавыш белән: “Кайгырма, улым, бирешмә, балакаем”, — диде.

Кадерлем, бәгырем минем, бердәнберем, газиз әниeм! Сине табигатең ничек шулай көчле яратты икән? Бу минутта, бәлки, башка ана булса, еларга яки мескенләнергә керешер иде. Ләкин минем әниeм андыйлардан түгел.

Тормыш ифрат авыр. Әниемнең эш хакы аз. Икмәк карточка белән генә бирелә. Ашаган төп ризык — бәрәңге.

Без Вахитов заводы янында бер фатирда яшәгәндә, әниемнең аягына брезент итек киеп кыш уздырганын яхшы хәтерлим. Аның кышкы суыкларда мәктәбеннән кайткач, сызланып, тезләрен уып, мич авызы каршында утырган чакларын онытасым юк.

Кыскасы, безнең эшләр бик үк мактанырлык түгел иде. Ләкин шуңа да карамастан без, әниле-уллы, үзебезне моңарчы бик бәхетле сизеп яши идек. Ник без бәхетсез булыйк: тормыш — илдәгечә, без һаман үсәбез, укыйбыз, куйган максатыбызга барабыз. Тик бу бәхет бүген, боздан ясалган бинадай җимерелде. Хәзер инде эшкә урнашу турында уйларга кирәк. *(202 сүз) (А.Расих буенча)*

Сугыш башлану

Мөнирә, йөзен куллары белән каплап, сугыш башланган сәгатьләрдә кайда булганын, нәрсә эшләргә әзерләнгәнен исенә төшерергә тырышканда, аның күз алдына Казанның күләгәле борынгы бакчасы килеп баса торган иде. Җәйге аяз көн. Шәһәрнең бөтен яшьләре паркка, спорт бәйрәменә җыелганнар. Меди-

цина институты студентлары арасында Мөнирә белән Таня да бар. Һәҗәр химия-технология институты студентлары арасында. Театр училищесы студентлары уртасында Ләләнең тавышы ишетелә. Надя — педагогия институты, Хафиз университет командасы белән килгәннәр.

Сәгать унбердә кроссны башлап җибәрделәр. Менә кызлар биш йөз метрга йөгерә башладылар. Надя Егорова башта ук иң алга чыкты. Надя артыннан ун-унбер адымнар гына артта калып, кыска аксыл чәчле бер кыз килә. Аның артыннан ук Таня һәм Мөнирә. Финиш янында гына аларны Ләлә куып җитте.

Бакча өстендә, яшел яфраклар шаулавына талгын музыка тавышы кушыла. Кызларның йөзләре көләч, аларны һични куркытмый. Киләчәк аларга шушы июнь күге кебек саф, болытсыз, матур булып күренә. Ләкин нидер булды. Музыка кинәт туктады, халык, ашыгып, парк үзәгендә урнаштырылган репродукторларга таба авыша башлады.

Радиодан иптәш Молотов сөйли иде. Кызлар аның сөйләвенең башын ишетмәделәр. Шуңа күрә башта сүзнең нәрсә турында булуын аңламадылар. Аннары барысы да аңлашылды — сугыш башланган. *(178 сүз) (Г. Әпсәләмов буенча)*

Китап

Китап... Ике катыргы арасына тыгызлап тутырылган чуар кәгазь. Бары шул гына, ә яхшылап уйлап карасаң, китап ул — адәм баласы уйлап чыгара алган могҗизаларның могҗизасы.

Могҗиза, чөнки Пушкин үлгән, Тукай үлгән, Гоголь, Толстой юк, ә без алар белән кара-каршы сөйләшкән кебек сөйләшәбез, алар нинди уйлар белән яшәгәннәр, язып калдырган китапларының битләрен ачып, без дә шул уйлар белән янабыз... Моннан ничә мең еллар элек яшәгән борынгы Мисыр, Рим, Һинд язучылары, галимнәре бүген безнең белән янәшә яшиләр, китаплары безнең алдыбызда. Без китап битендә борынгы Мисыр кызының матур елмаюын күрәбез.

Дәүләтләр яшәгән — беткән, халыклар яшәгән — сөяге дә калмаган. Ай калган, Кояш калган да китап калган... Таш китап, үлән китап, тире китап, ефәк китап, кәгазь китап калган...

Әйе, гомере буена Китап — кешенең аерылгысыз юлдашы. Ул халыклар белән халыкларны таныштыра, буыннар белән буыннарны кавыштыра.

Беренче китап XIйөздә Кытайда басылып чыга. 1445 нче елдан башлап бөтен Европага тарала. Татар телендә басылган беренче китап гарәп хәрефләре белән 1612 нче елда Лейпциг шәһәрендә чыга.

Италиядә Шәрык илләрендә чыккан китаплар киң таралган булган. Ләкин алар гарәп һәм фарсы телләрендә. Халык арасында шуңа күрә кулдан язылган

китаплар күп булган. Әле хәзерге көнгә кадәр галимнәр кулъязма китапларны таба торалар. *(180 сүз) (Ибраһим Газидән)*

Керпе

Керпе — бик кызыклы хайван. Аны ялан кул белән тоту мөмкин түгел, чөнки ул шунда ук чәнечкеле йомгакка әйләнә. Ә үзе кулга тиз ияләшә, йомарланмый башлый, маңгаендагы кыска йоннары астыннан кызыксынучан күзләре белән карап, ялтыравык төймәгә охшаган озын борынын чыгара, сөт һәм башка ризыктан авыз итә. Керпе җиләк, үлән, бака ашый.

Керпе кышны тирән йокыда үткәрә, азык запасы әзерләми. Көзен үзенә кечкенә чокыр казый, аның төбенә коры яфраклар түши. Кышкы салкыннар җиткәч, шул ятагына кереп чума. Апрель ахырында-май башында кышкы йокысыннан уяна.

Керпе баласы чукрак, сукыр, ялангач һәм энәсез булып туа. Туып берничә сәгать үтүгә, тәненә йомшак энәләр үсә башлый. Бераздан ул энәләр ныгый, катылана, аларда ак буйлар барлыкка килә. Әниләре бала керпеләрне йомгакланып төрелергә һәм сүтелергә өйрәтә. Соңрак ул аларны ризык эзләргә алып чыга. Бөҗәкләр, коңгызлар эзләргә өйрәтә. Гөмбәләр белән таныштыра. Бала керпеләр әниләре биргән дәрестән яшәү күнегүләре алалар.

Керпеләр алма һәм башка предметларны энәләренә чәнчеп ташыйлар, моның белән алар тәннәрендәге паразитларны бетерәләр. Ничек итеп дисезме? Алманың әче суы керпенең тиресенә агып төшә һәм андагыпаразитларны куркыта. Менә шулай итеп, керпеләр тирәлеккә җайлашалар *(176 сүз) (М. Рафиковтан)*

Туган авылым

Мин үземнең илемне, туган ягымны бик яратам. Ак карлы кышының да, алтын көзенең дә, чәчәкле җәенең дә кабатланмас матурлыгы бар безнең якларның. Тик шулай да мин язларга гашыйк.

Баш очында гына тургай талпына. Аның җыры зәңгәр һавада яңгырап тора да язгы кояш нурларында изрәп яткан кыр өстенә коела. Гөрләвекләр тавышына кушылып, сине хискә күмә, моңа чаклы йоклап яткан күңел кылларыңны тибрәтеп җибәрә.

Майның урталары. Авылның иң матур вакыты: көннәр җылы, ямьле, һава саф, йомшак, авылны урап алган кырларда төрле ашлыклар ямь-яшел булып үсәләр. Күкне тутырып тургайлар сайрый. Кырларны әйләндереп алган урманнардагы төрле агачлар куе, яшел яфракларга, чәчәкләргә күмелгән. Анда мең төрле кош сайрый: сандугачлар, күкеләр, тургайлар һәм башкалар.

Урманнарның аланнары төрле-төрле матур чәчәкләр белән бизәкләнгән. Ул чәчәкләр куе үләннең карасу кыяклары эченнән, күктәге йолдызлар кебек

күзгә карап, көлеп, елмаеп торалар. Куе агачлар эченнән вак ташлыклардан көмеш кебек сулы салкын чишмәләр мөлдерәп һәм чылтырап агалар. Авыл аркылы чыккан тирән генә, тар гына саф сулы инеш ямь-яшел болынны икегә аерып китә. Ул инештә, тәнгә сихәт бирә торган суыннан чыкмыйча, балалар, үрдәкләр, казлар җәй буе коеналар. Матур да соң безнең авыл! *(177 сүз) (М. Хәбибуллиннан)*

Ярдәм

Көз килде. Бакчадагы агачлар яфракларын коеп бетерде диярлек. Агачта калганнары исә аз гына кагылуга, җиргә сибеләләр. Кошлар да җылы якларга киткәннәр.Бары песнәкләр, чыпчыклар һәм ала каргалар гына калган.Алар кышын курыкмыйлар бит. Өч көн яңгыр яуды һәм суытып җибәрде. Аяк асты — көзге шикелле, боз. Сакланып басмасаң, егылырга бик мөмкин. Малайларга шул гына кирәк, алар чаналарын алып тауга киттеләр.

Таудан бер бабай төшеп килә. Бер кулына зур кәрзин тоткан. Икенче кулында — таяк.Бабай бер атлый да туктый, тагын атлый да туктый. ”Ничек төшәр икән инде бу бабай? Кәрзине дә авыр ахры,” — дип уйлады чана шуучы малай һәм бабай янына килде.Янында чанасы да бар иде. Малай карт янына килеп басты да аның кәрзинен алды: “Бабай, кәрзинегезне бирегез, аска алып төшәм, аннары үзегезне дә алырга менәрмен”, — диде. Бабай аңа: “ Ай акыллым! Кәрзинем төшсә, бик яхшы. Кәрзин булмагач, үзем әкрен генә төшәрмен әле!” — диде. Малай аңа:”Чанам зур минем, бабай, сез дә сыясыз”, — диде.Ул, бабайны утыртып, минем янымнан выжылдап узып та китте. Бабай бик шатланды.Миңа карады да малайны мактады: “Күрдеңме, кызым! Бигрәк яхшы малай икән! Капитан булыр ул!”— диде. *(178 сүз) (Д.Аппаковадан)*

Мактанчык алма

Ямьле, җылы яз көнендә алмагач бакчасында булган бу хәл. Бакчада бер яшь алмагач үсеп утырган. Аның әле бер генә тапкыр да алма биргәне булмаган. Яз җиткәч, бер генә бөртек чәчәк аткан да алмага бөреләнгән. Тирә-яктагы үсемлекләр барысы да моңа бик куанганнар, яшь чибәркәйне тәбрик иткәннәр. Кошлар үзләренең иң матур җырларын юллаганнар. Олы агачлар бик сөенгәннәр, кортлар ияләшмәсен өчен, көндез дә, төнлә дә аны саклаганнар.

Алма көзгә бик матур булып кызарып пешкән. Уңыш җыяр вакыт җиткәч, аны да агачыннан өзәргә булганнар. Ләкин Алма:

— Мин, матур алма, өзеп ашар өчен түгел! — дигән дә яфраклар арасына кереп качкан. Шулай берзаман бөтен бакчага бер Алма булып калган. Шуннан соң ул:

— Күрдегезме инде, куркаклар, мин матур гына түгел, батыр Алма да бит әле! — дигән.

— Курыкмыйча, шундый зур бакчада минем кебек батырлар гына кала!

Бүтәннәр аның соңгы сүзләрен ишетмәгәннәр. Аларның кышка әзерлек эшләре башланган: яфракларын коясы, ботакларын корткыч бөҗәкләрдән чистартасы булган.

Шул арада, күптән инде җай гына чыкканын көтеп торган алма корты, сиздермичә генә менгән дә Алманы тешләп алган. Алма, авыртуына чыдый алмыйча, үрле-кырлы сикергән дә, агачыннан өзелеп, җиргә төшкән. Бер генә түгел, әллә нихәтле корт кимереп бетергән үзен. Һәр алманың үз вакыты, һәр эшнең үз җае барлыкны онытмаска иде шул аңа. *(182 сүз) (Алмаз Гыймадиевтан)*

Туган мәктәбем

Унынчы сыйныф укучылары, мәктәптә күптән килә торган гадәт буенча, бәйрәм көненә багышланган кичәгә спектакль әзерлиләр иде. Мондый кичәләр бер традиция булып киткәнлектән, аңа мәктәпнең барлык элекке укучылары катнашырга тырыша, килә алмаганнары хатлар, телеграммалар җибәрәләр. Шуңа күрә соңгы көннәрдә телеграмма ташучылар мәктәп юлыннан өзелмәде. Алар берьюлы бишәр-алтышар телеграмма алып киләләр. Мәскәүдән, Ленинградтан, Киевтан, Барановичидан, Одессадан, Владивостоктан — кайдан гына юк ул телеграммалар! Иптәшләр бәйрәмгә катнаша алмаулары өчен кайгыралар, ләкин бу көнне алар, кайда гына булсалар да, үзләрен тәрбияләп үстергән, кеше иткән кадерле мәктәпләрен, хөрмәтле укытучыларын сөеп искә алачакларын белдерәләр.

Спектакль иртәгә билгеләнгән булса да, бүтән шәһәрләрдән һәм районнардан килгән кунаклар мәктәпкә бүген үк җыела башладылар. Кайчандыр шушында укыган, ә хәзер кайсы укытучы, кайсы инженер, кайсы агроном, кайсы врач, кайсы очучы булып өлгергән дәү абыйлар, дәү апалар, укучы балаларны шаккатырып, сыйныф бүлмәләренә кереп йөрделәр, парталардан, тәрәзә төпләреннән, кара такта кырыйларыннан үзләренә генә билгеле булган ниндидер тамгалар табып, бер-берләренә күрсәттеләр, көлештеләр, тәрәзәләрдән үрелеп, каядыр тышка карадылар, матур оранжереяләргә охшаган, күз явын алырлык чәчәкләр, мәңге яшел үсемлекләр белән бизәлгән озын, якты коридорларда озак-озак сөйләшеп йөрделәр. *(180 сүз) (Г.Әпсәләмовтан)*

Икмәк

Кулыма икмәк алганда, еш кына сугыш еллары исемә төшә. Сугыш елларында күңелгә сеңеп калырлык күңелне тетрәндererлек вакыйгалар шактый күп булды. Ләкин шуларның берсе аеруча хәтергә уелып калды.

Мин 1945 нче елның август башларында күргән бер күренешне оныта алмыйм. Без, бер группа солдат һәм сержантлар, туган илгә кайтып бара идек. Һәркайда җимереклек, яндырылган авыллар, шәһәрләр. Авылларның исемнәре топографик картада гына калган. Исән калганнар, җимерекләрне бетерү, тыныч тормыш башлап җибәрү белән мәшгуль иде.

Шулай кайта торгач, безнең эшелон кечкенә генә станциягә килеп туктады. Төшәргә команда булмаганга күрә, без ачык ишектән генә тирә-якны күзәтеп торабыз. Шул вакыт безнең вагон янына 7–8 яшьләрдәге бик ябык малай килеп басты. Кызыксынып, бер сүз әйтмичә, малайны күзәтәбез, үзебезнең балаларыбызны күз алдына китерәбез. Аның көчсез генә тавыш белән “ Абыйлар, ипиегез юкмы, ипи бирегезче”, — дип соравыннан эсселе-суыклы булып киттек. Ул тавыш әле дә колак төбендә яңгырап тора шикелле.

Менә бит ул каһәр суккан сугыш! Без, аяусыз һөҗүмнәрдә иң якын дусларыбызны югалтканда да сыгылып төшмәгән кешеләр, күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, читкә борылдык...

Башка станцияләрдә дә икмәк сораучыларны азмы-күпме шатландырдык, паекларны балаларга өләштек. Әмма беренче очраган малай онытылмый. Табынга утырган саен, икмәк сораган малай искә төшә. *(181 сүз) (Вакытлы матбугаттан)*

Әтием турында

Минем сезне әтием белән таныштырасым килә. Минем әтием — татар халкының танылган һәм талантлы композиторы Салих Сәйдәшев. Аның балачагы турында миңа әбием сөйли иде. Аның сөйләүләреннән мин шуны белеп калдым: әтием бик кечкенәдән музыка тыңларга, җырларга яраткан, гармунда уйнарга да бик иртә өйрәнгән.

Әтием көндәлек тормышта йомшак, иркен күңелле кеше булды. Мин аның безгә, балаларга, кычкырганын хәтерләмим. Ул, гомумән, тупаслыкны яратмый иде. Чыннан да, без аның Әминә исемле апасын бик яратуын, олылавын, шулай ук җизнәсе Шиһап Әхмәровны бик ихтирам итүен күреп үстек.

Миңа әтиемне иҗат итеп утырган чакларында күзәтергә туры килмәде диярлек. Ник дигәндә, ул пианино янында утырып эшкә тотынса, без аның бүлмәсенә кермәскә, мөмкин кадәр аңа комачауламаска тырыша идек. Дөрес, әсәрләрен иҗат иткәндә, ул шагыйрь яки драматург белән киңәшә торган иде. Бигрәк тә аның драматург Тажи Гыйззәт белән бергә эшләгән чаклары минем хәтеремдә калган. Эш бүлмәсенә кермәсәм дә, кайвакыт аның уйнавын, көйләрен кат-кат тикшереп каравын сәгатьләр буе йотлыгып тыңлый идем.

Аның иң яратып башкарган көйләре — татар халык көйләре иде. Ә үз әсәрләрен ул бары тик тыңлаучылар соравы буенча гына башкара иде.

Минем әтием — Салих Сәйдәшев — тыйнак һәм эш сөючән кеше иде. *(184 сүз) (А. Сәйдәшев буенча)*

Дан сиңа, туган илем!

Җиңү!

Менә ул, язгы бәрәкәтле яңгыр алдыннан күк күкрәгән төсле тавыш чыгарып, бәйрәм салютларыбыз яңгырый һәм энҗе кебек якты ракеталарның нуры белән тыныч күгебезне балкыта. Бу көн бик азга гына булса да югалту кайгысын, ачысын оныттырып торды. Бөтен ил шатлык кочагына ташланды. Бик кыйммәт бәя түләнгән шатлык көне иде ул.

Без аңар дүрт елдан артыкка барган сугыш ялкыны һәм янгын төтене аша килдек. Илебезнең йөрәге — изге Мәскәү янындагы траншеялардан, Идел дәрьясының текә ярларыннан килдек. Шәһәрләребез, авылларыбызны азат итү өчен барган көрәшләрдә батыр сугышчыларыбызны югалттык без.

Йөрәкләребездә:

– Җиңү безнең якта булыр! — дигән нык иман белән килдек.

Һәм менә ул — яхшылыкның явызлыкны тарихта беренче тапкыр шушындый бөек тантана белән җиңүе! Фашизмның канлы байрагы бәреп төшерелде. Безнең урамда хәзер бәйрәм!

Җиңү!

Кырык беренче елның кызу җәендә авылларыбызны, шәһәрләребезне җимергәндә, кырларыбызда үскән игеннәребезне танклар таптаганда ул әле алга чакыручы өмет иде. Туганнарыбызны, газиз кешеләребезне караңгылатылган юллар буенча озатканда һәм алардан борчылып хат-хәбәр көткәндә, без аның турында хыяллана, уйлый гына идек әле. Бүген ул чынбарлыкка әйләнде һәм дошманның башкаласы өстендә, әкияттәге ут кошы төсле, ал байрак булып югары күтәрелде. *(176 сүз) (Кави Нәҗмидән)*

Дуслар

Миша — рус малае. Татарлар янында үсте. Бик әйбәт татарча сөйләшә, татар җырларын яратып җырлый. Башта әтисе аны шәһәргә рус мәктәбенә укырга бирде. Ни өчендер, Миша бик авыр укыды, бигрәк тә арифметиканы аңлый алмый иде. Миша уенны бик ярата иде шул. Татар малайлары белән уйнау комачау итә, дип сөйләнде әти-әнисе. Тиздән аларга шәһәрдән квартира бирделәр. Анда Миша яхшы гына укып китергә тиеш иде, тик алай булып чыкмады.

Миша Идел буен оныта алмады. Балачактан ук балык тотарга яратты. Озаклап Идел яры буенда уйланып утырырга ярата, үсемлекләр, бөҗәкләр белән сөйләшә, табигатьне тыңлый белә. Андагы бу сәерлекләрне Тәүгиз кенә

аңлый. Шуңа күрә Миша укуда начар билге алса, өйдә берәр күңелсезлек чыкса, тизрәк Тәүгизләргә килеп җитә. Менә бүген дә мәктәптән Миша туры аларга кайтты.

Алар сарайдан озын-озын кармаклар алып чыктылар.

—"Нота" шигырен ятларга бирделәр, — диде Тәүгиз. — Моннан элек "Мокамай"ны сөйләттеләр. Миша да Такташның берничә шигырен яттан белә иде.

Тәүгиз гаиләдә бердәнбер бала иде. Алар зур, якты, яңа йортта яшиләр. Мишалар алты бала үстеләр, аларның йортлары да кечкенә генә иде. Аның әти-әниләре шәһәргә күчү теләге белән яшәгәнлектән, йортларын яңартмадылар. Шуңа күрә Миша гел Тәүгизләрдә булды, хәтта аларда кунарга да кала иде. Шул вакытларда алар шигырьләрне бергә ятладылар. *(180 сүз)*

Ожмах кошы

Әбисенең әкият сөйләгәнен тыңларга ярата Ләйлә. Тавышы шундый йомшак, утырган җирдән изрәп, татлы йокыга киткәнеңне сизми дә каласың. Ә әкиятләре — тын да алмый тыңларлык кызык, каян шулкадәр белеп бетерә торгандыр.

— Борын-борын заманда, саескан сутник, үрдәк үрәтник булганда — дип, ул бүген ожмах кошы турында әкият сөйләде. Ожмах кошы Ләйләгә хәтта төшенә дә керде. Нәкъ әбисе сөйләгәнчә, аллы-гөлле каурыйларын балкытып, шау чәчәкле ожмах бакчасында кукыраеп йөри имеш. Шул кошның канатына гына кагылсаң да дөньяда иң бәхетле кеше буласың икән.

Бәхет дигәне нәрсә буладыр инде. Ләйлә бик аңлап бетерми. Аңа бит әле биш яшь кенә. Әтисе әнисенә: "Син — минем бәхетем!" — ди. Әнисе Ләйләне кочаклап: "Син — минем бәхетем! — ди". Матур күлмәк алсалар — бәхет, шоколад белән сыйланса — бәхет, әнисе эшенә алып барса — бәхетнең дә бәхете!

Беркөнне әбисе каты авырып китте, урыныннан тормас булды. Бик борчылды Ләйлә. Инде аңар әкият сөйләр кеше дә калмады....

Кызчык әбисе яткан бүлмәгә кереп китте. Нәни учларын әбисенең маңгаена куйды, мәтрүшкәле чәен эчәргә булышты. Бүген Ләйлә үзе аңа ожмах кошы турында әкият сөйләде.

— Менә ул кошны әтием тотып алып кайтса, син терелер идең, әйеме, әбием! — дип хыялланып та алды.

Әбисе хәлсез куллары белән оныгының чәченнән сыйпап елмайды:

— Ожмах кошым — ул син, нәп-нәни зу-у-ур бәхетем! *(186сүз) (Р.Шәриповадан)*

Таныш моң

Ул кичне фронттан аеруча күңелсез хәбәр килде.

Күземә йокы кермәде. Ниндидер ташландык бер сарайда бөркүдән һәм авыр уйлардан йоклый алмый газапланып ятканнан соң, урамга чыктым. Урам буш һәм тын иде. Үз-үземне кая куярга белмичә, ачынып, тротуар буйлап киттем, көннең суыклыгын да, урамның караңгылыгын да тоярлык хәлдә түгел идем. Патрульләр берничә мәртәбә туктатып, пропуск сорады.

Күпме йөргәнмен, хәтерләмим. Ничектер, тар гына бер тыкрыкка барып чыктым. Шунда кинәт тынып калдым. Каяндыр әкрен генә, зәгыйфь кенә булып скрипка тавышы ишетелә иде. Башта мин колакларыма ышанмадым. Саташам дип торам. Безнең көй бит бу! Татар көе! "Әллүки"! Туган яклардан ераста әлеге көй аеруча кадерле иде.

Мин, аның әкрен генә, зәгыйфь кенә чыккан моңы агышына бирелеп, дөньядагы барлык нәрсәмне оныттым, берничә минут шулай басып тордым. Көй берничә тапкыр кабатланды. Ул һәр юлы, үзенең һәр авазы белән мине биләгәннән-били барды. Мин, ниндидер эчке көчкә буйсынып, аны эзләп, ишегалдына кереп киттем. Ләкин ул анда, мин кергәч, кинәт югалды.

Яңадан урамга атылып чыктым. Инде ул урамда ишетелми иде. Югалды...

Юк, югалмаган икән, ул яңадан яңгырый башлады. *(182 сүз) (Афзал Шамовтан)*

Татарларның милли бәйрәме — Сабан туе

Сабан туе — элек-электән татар халкының яраткан бәйрәме. Сабан туе — ул язгы кыр эшләрен уңышлы башкарып чыгу, булачак уңыш бәйрәме. Борынгы чорларда Сабан туе яз һәм табигатьнең җанлануы бәйрәме булган. Аның мең еллык тарихы бар. Сабан туе бәйрәме Идел буе Болгары дәүләтендә үк уздырылган булган.

Сабан туе Идел буенда яшәгән барлык милләтләрнең дә уртак бәйрәменә әйләнде. Анда татар халкы белән бергә рус, мари, удмурт, башкорт һәм башка халыклар да катнаша.

Сабан туенда иң зур ярыш — көрәш. Татар көрәшендә сөлге тотып көрәшәләр. Һәр көрәшче кондәшенең биленнән сөлге белән урап тота һәм аны җиргә егарга тырыша. Көрәшне малайлар башлап җибәрәләр. Аннары , чиратлашып, мәйданда яшүсмерләр, егетләр, урта яшьләрдәге ирләр көрәшә. Кондәшен аркасына яткырган кеше җиңүче була. Көрәштә батыр калучыга тәкә һәм кыйммәтле бүләк бирәләр.

Сабантуенда икенче зур ярыш — ат чабышы. Атлар 5–8 километр ераклыктан мәйданга чабып керәләр. Бу ярышта беренче килгән атның хуҗасына да зур бүләк бирәләр, ә атның муенына яулыклар, сөлгеләр бәйлиләр. Иң соңыннан килгән атның хуҗасы да бүләксез калмый.

Мәйданда кызыклы халык уеннары оештырыла. Ярышлар һәм уеннар беткәч, кешеләр өйләренә таралалар. Һәр йортта табын әзерләнә, бәйрәм ашлары пешерелә. Кичен яшьләр өчен җыр-биюләр дәвам итә.

Сабан туе — күңелле һәм шатлыклы бәйрәм. *(180 сүз) (Вакытлы матбугаттан)*

Яшәү өчен көрәш

Тормыш бераз эзгә төште. Күңел басылды. Иркенләп язарга, укырга мөмкинлек туды. Больницадагы кебек, кырыеңда ыңгырашып ятучылар юк. Карарга әнисе бар. Аналарның бөтен мәхәббәте, бөтен җылысы ярдәмгә мохтаҗ балаларга тиючән. Фәнияр да бу хакта белә: язмыш ныграк кыерсыткан саен, әнкәсенең якынлыгын күбрәк тоя ул. Ананы дөньяда һични алыштыра алмый. Ул — кешелекне тотып торучы алтын багана. Әмма яшьлек ярсуыннан тау чишмәседәй ургып торучы йөрәккә ана назы гына аз, ана кайгыртуы гына җитми. Күңел үзенең ишен эзли. Куанычларың булганда бергә куанырлык, кайгы-хәсрәт килгәндә — юатырлык, егылганда — кул сузарлык, ялгышканда — төзәтерлек, эшләп арганда — иркәләрлек, назга сусаганда кочагында эретерлек кеше табасы килә. Ә Фәнияр кебек кешеләргә иш табу кыен эш. Шуңа күрә ул үзенең авыруын капларлык эшләр башкарырга, тормышта яшьтәшләреннән бер як белән дә калышмаска тели, туктаусыз көрәшә. Фәниярга бер генә җиңүнең дә көрәшсез килгәне юк әле. Кулына каләм тотып бер юл шигырь язар өчен дә, замандашларыннан артта калмаска теләп, тырышып-тырышып укыр өчен дә, хәтта мәхәббәт өчен дә көрәшергә, язмыш куйган ятьмәләрне ертырга кирәк аңа. Көрәш ул, Сабантуйларда кулыңа тастымал урап, кемнәрнеңдер биленнән алу гына түгел. Тормыш өзлексез көрәштән гыйбарәт: көчлеләр ега, көчсезләр егыла. *(180 сүз) (Ф.Яруллиннан)*

Урман

Аю, икесе дә бертөрле бик озын һәм бик яшел ике агач янына килеп, алар белән дә таныштылар. Болар Нарат Нуриев белән Чыршы Шәрипов иде. Алар сүзне болай башлап җибәрделәр:

— Безнең кадеребезне, матурлыгыбызны беләсең килсә, Аю агай, син бөек шагыйрь Г.Тукай шигырьләрен тыңлап кара һәм илебезнең олы рәссамы И.Шишкин картиналарына күз сал. Безне мактап, тиккә генә шигырь язмаганнар, безнең матурлыгыбызга сокланып, тиккә генә картиналар эшләмәгәннәр алар. Аннары шуны да әйтеп үтик, Аю агай: безне бит теләсә нинди төзелешләрдә дә файдалана алалар.

Аю, агачлар белән саубуллашып, өенә кайтырга җыенганда гына, Урман телгә килде:

— Мин биләп торган мәйдан болай гына түгел иде. Ләкин ниндидер саксыз кешеләр, янгын чыгарып, мине харап иттеләр. Әгәр миндәге бик күп агачларны олы кешеләр дә, балалар да сакласалар, аларны урамнарга, бакчаларга, паркларга, юл буйларына күпләп утыртсалар һәм яхшылап карап үстерсәләр, бу агачлар бөтен дөньяны яшеллек белән каплап алырлар иде. Агачлар, яшеллек үскән җирдә һава саф була. Урман эчендә җәнлекләр үзләренә оялар, өннәр ясыйлар, балаларын үстерәләр. Минем аланнарымда тәмле җиләкләр, матур чәчәкләр, файдалы дару үләннәре үсә. Мине саклагыз, хәзинәләремнән авыз итегез, егылган агачлардан чистартыгыз.

— Бу мәгънәле сүзләрне онытма, тизрәк яз! — диде Аю Куянга. *(180 сүз) (Г.Галиев буенча)*

Очрашу

Илдарны мәктәпкә очрашуга чакырдылар. Ул үзенең малай чагын исенә төшерде. Шәһәрнең хөрмәтле кешеләре алар классына да шулай килә торганнар иде. Җиденче класста укыган чакларында, алар генерал Булатов белән очраштылар. Класстагы малайлар аның күкрәгендәге орден белән медальләрен әллә ярты сәгать санадылар инде. Берлинны алган генерал аларга ул көнне бик күп гыйбрәтле вакыйгалар сөйләде.

Илдарлар ул көнне генералның сөйләгәннәрен авыз ачып тыңлап утырганнар иде. Ә ул үзе соң — биографиясен яза башласа, ярты биткә дә тутыра алмаган бер егет — балалар каршына барып ни сөйләр? Идел буе зонасында беренчелекне алу шаккатарлык эш түгел әле ул. Бу әле Илдарның үзе өчен дә зур спортка килүнең беренче адымнары гына. Киләчәктә, бәлки, ил буенча чемпион булыр әле ул, ә бәлки дөнья күләмендә дә. Тренеры аңа зур өмет баглый. Анысы әле киләчәк эше.

Берничә көн очрашу турында уйлап йөргәннән соң, ул аны Менжинский клубында уздырырга булды, укучыларны шунда чакырды.

Стенага эленгән портретлардан органнарда хезмәт итүче атаклы спортчылар карап тора. Араларында ил күләмендәге ярышларда катнашучылар да бар икән. Кайсы чаңгы буенча спорт мастеры, кайсылары — йөзү буенча. Шкафларда алар яулап алган кубоклар. Илдар Кәримов, аларның һәркайсы турында иркенләп сөйләде.

Соңыннан, кино залына кереп, “Беренче перчатка” дигән кино карадылар. *(180 сүз) (Л.Ихсанова буенча)*

Милли китапханә

Татарстанның Милли китапханәсе Казандагы иң матур йортларның берсендә урнашкан. Аның яныннан битараф кына узып китеп булмый. Бу бинаны фабрикант Ушков салдырган, соңыннан ул китап йортына әверелгән.

Заманының шактый зыялы кешесе И.А.Второв гомере буе китап җыйган. Аның китапханәсендә төрле телләрдәге китаплар, журналлар тупланган. Бу байлык мирас булып, аның улы — Н.И.Второвка күчкән. Николай Второв — Казанда җәмәгать китапханәсе ачылуга зур өлеш керткән кеше. Петербургка күчеп киткәндә, ул әтисе китапханәсен шәһәр идарәсенә бүләк иткән. Шулай итеп, 1865 нче елда Казанда китапханә ачылган.

Арыслан, төрле кош сурәтләре белән бизәлгән стеналар, борынгы баскычлар. Уңда да, сулда да, каршыда да — ишекләр, каталоглар, киштәләр…

Милли китапханәдә борынгы кулъязмалар, сирәк китаплар бүлеге дә бар. Татар китаплары, туган якны өйрәнүгә багышланган басмалар бүлеге дә эшли. Дөнья әдәбияты, сәнгать бүлеге, фәнни-методик әдәбият бүлеге… Газета-журналлар өчен аерым бүлмәләр каралган. Бу йорт 3 миллионнан артык китапны сыйдыра.

Белеп торыгыз: биредә беркайчан да “китап юк” димиләр. Үзендә кирәкле китап юк икән, компьютерга басып, университет китапханәсеннән, бөтен Татарстаннан эзлиләр. Анда да бу китап булмаса, Россия Дәүләт китапханәсенә яки Санкт-Петербургның Үзәк китапханәсенә мөрәҗәгать итәләр. Инде әлеге китап анда да юк икән, чит ил китапханәләренә чыгалар. Милли китапханәдә халыкара китап алмашу бүлеге бар. Татарстанның Милли китапханәсе дөньядагы 83 илнең китапханәләре белән килешүләр төзегән… Кешелекнең чын тарихы Китап дөньяга килгән чордан башлана. Китап, халыкларны гасырлар буена тәрбияләп, ышаныч һәм өмет биреп, киләчәккә алып барган. *(212 сүз) (“Татарстан Республикасының Милли китапханәсе” китабыннан)*

Прочитайте. Озаглавьте текст. Разделите и назовите микротемы

Йортлар язмышы да кешеләр язмышына охшаган: төзеләләр, яңа чакта бөтен тирә-якны бизәп торалар, аннары әкренләп картаялар, тузалар, тын гына үләләр. Йортлар язмышы кешеләр язмышы белән уртак: сугышларда яраланалар, җимереләләр, афәт килсә, вакытсыз искерәләр, тузалар. Тыныч, мул елларда ишәяләр, матурланалар. Йортларга карап илнең иминлеген белеп була.

Калалардагы таш йортларның гомере озын. Аларны салган кешеләр күптән юк инде, әмма шушы йортларда аларның матур хисләре, якты хыяллары, тормышы һәм язмышы саклана. Калалар үзләрендә кешелек тарихын саклыйлар. Җир йөзенә яңадан-яңа буыннар килә, һәрберсе үзенчә йортлар сала, һәрберсе шәһәрне үзенчә яхшырта һәм үзенчә бизи. Шул рәвешле калада бер-берсенә охшамаган төрле йортлар барлыкка килә. Шулай да һәр каланың үз йөзе, үз үзенчәлекләре, үзенә бер бөтенлеге бар. Калалар калаларга охшамый, чөнки аларны төзегән халыклар да бер-берсенә охшамаган.

Гаҗәеп кала Казан! Нинди генә йортлар, нинди генә биналар юк биредә. Ак стеналы кремль, гади формада, ләкин искиткеч матур Сөембикә манарасы, университет колонналары, Петропавловский соборының бизәкле манаралары һәм челтәрле тәрәзәләре. Казанны башка калалардан аерып торган, аны матур һәм күңелгә якын иткән үзенчәлеге шунда: биредә кеше үзенең табигать баласы икәнен онытмый. *(М.Маликова буенча)*

Икмәк

Бу сүз — ана исеме белән торырлык олы сүз. Икмәк турында бер генә көн уйламый калган кеше бармы икән дөньяда? Күпме шигырь, күпме роман язылган икмәк турында! Шулай да мин үземнең сүзләремне “Без икмәкне ихтирам итә беләбезме?” дип башларга телим.

Беркөнне бер танышым белән иртәнге тыныч, матур вакытта Аккош күле янындагы яшел алан аша сузылган сукмак буйлап сөйләшә-сөйләшә кайтып килә идек. Менә шушы карап туймаслык гүзәл аланда, аллы-гөлле чәчәкләр үскән палас өстендә ертылып ташланган газета кисәкләре, буш консерв савытлары, шешә ватыклары күреп сәерсенеп калдык. Хәтта бер агач төбендә бербөтен икмәк аунап ята иде.

Үзебез дә сизмәстән шул икмәккә карап тукталдык та телсез калган кебек булдык. Шулай рәхимсез ташланып калдырылган изге икмәк өчен безгә бик уңайсыз булып тоелды. Дөресен әйткәндә, без оялдык. Кемнеңдер бу мәрхәмәтсезлеге өчен без дә җаваплы идек шикелле.

Бу икмәкне кем ташлаган? Ул рәхимсез бәндәнең исеме ничек? Ул икмәкнең нәрсә икәнлеген, кайда һәм ничек үскәнлеген беләме икән?

Юктыр. Әгәр ул икмәк үскән җирләргә яңгыр гына түгел, бәлки иген-ченең маңгай тирләре тамганны белсә, иген үскән җир туфрагында кояш җылысы гына түгел, хезмәт кешесенең күңел җылысы да калганлыгын белсә, болай эшләмәс иде. Урамнарда, паркларда, вокзал буйларында аунап яткан икмәк телемнәре булмас иде. Аңа намусы мондый эш эшләргә рөхсәт итмәс иде. Ул беркайда да язылмаган законны белер иде Бу закон икмәккә ихтирам, кешегә мәхәббәт турында. Аны үтәү — һәркемнең изге бурычы. *(218 сүз) (Н.Дәүли буенча)*

Батырлык нинди була?

Дәү апасы белән автобуста авылларына кайтып килеше иде Әнвәрнең. Көн кызу, һәммәсе дә әлсерәшеп, йокымсырап утыралар. Кинәт алгы урындыктагы кыз чәчрәп сикереп торды, кычкырып җибәрде хәтта. Янындагы олы яшьтәге бер абый авырып киткән икән. Авып ук төшкән. Пассажирлар югалып калды, ыгы-зыгы башланды. Әнвәр сизмәде дә, дәү апасы кай арада торып киткән дә

теге абыйга ашыгыч ярдәм күрсәтә башлаган. Салонга дару исе таралды. Ниһаять, киеренкелек бетте, авыру торып утырды. Дәү апасына төрле яклап рәхмәт яудырырга тотындылар. Ул исә, берни булмагандай, янәдән үз урынына килеп утырды. Әнвәр генә шактый озак тынычлана алмый азапланды. Кайтып җиткәнче дәү апасына карыйсы гына килеп торды.

— Син, дәү апа, чын батырлык эшләдең. Юкса синең врач икәнлегеңне монда берәү дә белми иде бит, — диде. Апасы елмайды гына: — Син бигрәк арттырып җибәрәсең инде! — диде. — Батырлык шундый була димени?! Әледән-әле исенә төшеп тора бу хәл Әнвәрнең. «Батырлык идеме?» дип икеләнә. *(140 сүз) (Л. Гыймадиевадан)*

Ашыгудан ни файда?

Әби беркөнне иртәнге сәгать дүрттә үк күрше Сәлим абыйның машинасына утырып районга китте. Кәҗәне көтүгә куарга миңа кушты: «Сәгать челтерәгәч тә торырсың, улым, яме», — дигән булды. Челтерәде будильник. Юрганнан башны да чыгармыйча, кул белән генә мендәр янындагы урындыктан капшана-капшана эзләп таптым аны, төймәсенә басып авызын томаладым. Икенче якка борылдым да тагын йокыга киттем, нигә ашыгырга? Йокыдан сәгать унда гына уяндым. Дөрес, кәҗәм көтүдән калды калуын. Аның каравы үзен кич белән алып кайтасы булмады.

Күрәсезме, ашыкмаудан гел файда! Тик менә каникул гына ашыкты — тиз үтте. Иртәгә Беренче сентябрь икән бит. Шуңа күрә бүген китәм. Казанда әни каршы алырга тиеш. Әнә станция дә күренде инде. Тагын бер чакрым чамасы атлыйсы калгандыр. Чү! Минем поезд килеп туктаган да түгелме соң? Әллә инде кузгалып та бара? Кузгалды шул. Китә бит, китә. Бетте баш. Бүген башка поезд юк бит инде. Их!

Үзем ашыгып атлаган булдым бит әле. Ашыга-ашыга шабыр тиргә баттым. Тик ни файда соң?! Үзегез күреп торасыз — ашыгудан файда юк. *(156 сүз) (В. Нуриевтан)*

Чит итмәде

Кошларның ят кош йомыркасыннан бала чыгаруы беркемне дә гаҗәпләндерми. Ә хайван һәм җәнлекләр белән андый хәлнең булганын ишеткәнем юк иде. Сирәк булса да була икән.

Көтүче абый урманнан бик кечкенә тиен балаларын алып кайта. Алар бик хәлсез булалар. Безнең урманнарда тиеннәр бик аз. Беткән дәрәҗәдә диярлек. Бу ике тиен баласы үлсә, алар тагын да кимерләр. Шуны уйлап, абый аларны терелтергә тырыша. Аларга сөт эчертәсе килә. Ләкин алар эчә белмиләр. Белмиләр һәм теләмиләр дә. Инде нишләргә? Көтүче абый уйлана башлый.

Күршеләренең этләре яңа гына балалаган иде. Абый шуны исенә төшерә. Актүшнең өч көчеге барлыгын ул белә. Этнең балаларын имезгәнен дә күргәне бар. Әниләре төсле аклы-каралы көчекләр — бик шаяннар. Гел уйнарга гына торалар. Көтүче абый тиен балаларын күршеләрнең эт оясына кертеп куя. Үзе күзәтеп тора. Эт тиен балаларына тимиме? Аларны кабып йота күрмәсен! Бераз карап торгач, ана эт тиеннәр янына килә. Аларны төрле яклап карап чыга. Аннары ялап куя. Димәк, Актүш аларны кабул итә. Шулчак көтүче абый да, тыныч-ланып, эшенә китә.

Хәзер авыл урамында, ана эткә иярeп, көчекләр генә түгел, ә тиен балалары да сикергәли. Башта бу күренешкә гаҗәпләнсәләр дә, авыл кешеләре дә күнектеләр. Алар бу гаилә дуслыгына сокланып елмаялар гына. *(180 сүз) (Вакытлы матбугаттан)*

Куркаклык бизәми

Раушания — сыйныфта иң матур кыз. Моның шулай икәнлеген бөтенебез белә. Әхәт тә белә, ләкин белеп кенә ни файда? Менә Раушания Әхәтне матур итеп күрсен иде ул. Юк шул! Әз генә дә игътибар итми. Бәлки, игътибар да иткән булыр иде — Әхәтнең буе бик кечкенә. Әнисенең кер юу машинасыннан әз генә биегрәк. Ләкин бик дуслашасы килә шул Раушания белән.

Их, берәр батырлык эшләсәң иде ул! Әйтик, Раушания суга бата башлый... Әхәт аны коткара... Яисә кызны зур овчарка таларга җыена. Шунда Әхәт йөгереп килә дә, “рраз!”, “рраз!”... Хыялларның чиге-чамасы юк иде.

Беркөнне Әхәтне, Раушанияне һәм сыйныфтагы тагын өч укучыны район үзәгенә математика буенча уздырылган олимпиадага җибәрделәр. Олимпиада яхшы узды.

Соңыннан, барысы бергә кереп, ашханәдә тамак ялгадылар. Ашаганнан соң, укытучы апалары берәр сәгать ял итәргә рөхсәт бирде. Шунда Әхәт:

— Раушания, әйдә, әнә теге супермаркетка барып киләбез, — диде, бераз дулкынланып. Кыз риза булды. Теләгән әйберләрен алып, кибеттән чыгып барганда, көтмәгәндә, алар каршына Әхәттән дә бәләкәйрәк буйлы бер малай килеп басты.

— Сәлам, чибәркәй, телефоның бармы? Бир аны миңа! Тизрәк! — диде ул. Әхәт катты да калды. Нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачты... әмма дерелдәгән иреннәре арасыннан сүз чыкмады. Шунда Раушания кулындагы сумкасы белән хулиган малайга китереп сукты. Ялгыш кына Әхәткә дә эләкте. Бу тавышка кибет эченнән кешеләр йөгереп чыкканда, бәләкәй буйлы башкисәр табан ялтыраткан иде инде. Раушания асфальтта башын тотып утырган Әхәт янына чүгәләде дә:

— Авыртамы? Гафу ит, ялгыш эләкте, — диде. *(210 сүз) (А.Гыймадиев)*

- **Язма эшләрне бәяләү критерияләре**

Укучыларның тел һәм сөйләм материалын үзләштерү дәрәҗәсен яки аларның гомуми грамоталылыгын диктант, изложение, сочинение яздырып тикшереп була.

Уку елы ахырында имтихан буларак үткәрелә торган (Дәүләт йомгаклау аттестациясе — ГИА-9, ГИА-11) язма эшләрне (безнең очракта диктант, изложениене) бәяләү түбәндәгеләрдән чыгып башкарыла.

Укучы диктант текстында өйрәнелгән темалар буенча орфограмма һәм пунктограммаларны яхшы белергә, хаталар ясамаска тиеш. Контроль диктантта төзәтүләр күп булса, билге бер баллга төшәргә мөмкин.

Изложение яздыру өчен, матур әдәбият әсәрләреннән өзекләр, хикәяләр, аерым текстлар алына. Изложение ярдәмендә укучының тема эчтәлеген ача белү осталыгы, лексик байлыгы, орфография, грамматика, пунктуация өлкәсенә караган грамоталылыгы тикшерелә.

- **Диктантны бәяләү**

Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаса “5” ле куела (1 орфографик, 2 пунктуацион хата булырга мөмкин).

2 орфографик, 2 пунктуацион яки 1 орфографик, 4 пунктуацион хаталы эшкә “4”ле куела.

4 орфографик, 4 пунктуацион яки 3 орфографик, 6 пунктуацион хаталы эшкә “3”ле куела.

6 орфографик, 5 пунктуацион яки 5 орфографик, 8 пунктуацион хаталы эшкә “2”ле куела.

- **Изложениене бәяләү**

Изложениене бәяләгәндә, фикернең логик эзлеклелегенә, эчтәлекнең тулы, дөрес бирелүенә, язма сөйләмнең камиллегенә, грамоталы итеп яза алу дәрәҗәсенә игътибар ителә. Изложение өчен ике билге куела: беренчесе — эчтәлек һәм сөйләмне дөрес оештыра алуга, икенчесе — грамоталылыкка.

Тема тулысынча ачылган, эчтәлеге һәм стиль берәмлеге сакланган эшкә “5” ле куела (1 орфографик, 2 пунктуацион яки 2 грамматик хатасы булырга мөмкин).

Текстның эчтәлеге темага, нигездә, туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлар җибәрелсә, 1–2 фактик, 1–2 техник хатасы булса, 2 орфографик, 2–3 пунктуацион, 1 грамматик хатасы булган эшкә “4” ле куела.

Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, 3 фактик, 2–3 техник хатасы булса, 3 орфографик, 4 пунктуацион, 2 грамматик хатасы булган эшкә “3”ле куела.

Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталар күп булса (5 тән артып китсә), орфографик хаталарның саны 4 тән артса, пунктуацион хаталарның саны 5 тән, грамматик хаталар саны 3 тән артса, “2” ле куела.